ОНЛАЙН АЛДАУ

2022 елның гыйнвар-февралендә республикада киберҗинаятьләр саны кимегән

> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ

Татарстан Президенты имзалаган яңа законнар

> 4–5

НӘФЕСНЕ ЙӨГӘНЛИСЕ

Өйләрне складларга әйләндерү маршы озакламый тукталырга тиеш

> 7

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 42 (28815) | Шимбә | 26 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Мәдәният

Милли геройлар, яшь режиссерлар, «импортланган» рухи кыйммәтләрне үзебезнекенә алыштыру, яшьләрне мәдәният учакларына җәлеп итү – Татарстан Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы утырышының төп мәсьәләләре әнә шул булды. Милли мәдәниятне кайгыртырга соңга калмадыкмы? Ул үзебезне канәгатьләндерерме?

vk.com

СОҢЛАМЫЙК...

Татарстан Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы утырышы Рөстәм Миңнехановның мәдәният хезмәткәрләрен һөнәри бәйрәмнәре белән котлавыннан башланды. Президент фикеренчә, бүгенге вазгыятьтә бу һөнәр ияләренең әһәмияте аеруча зур: «Бүген Россия Көнбатыш тарафыннан гаять зур басым астында яши. Ялган мәгълүмат һәм фейклар таратып, безнең илне һәм халкыбызны ямьсез яктан күрсәтергә тырышалар. Традицияләребез һәм рухиятебезгә таянып, дәүләтебезне, бәйсезлегебезне саклап калырга телибез икән, без бүген бердәм булырга тиеш. Россия һәрвакыт мәдәни традицияләре белән көчле булды», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, республикада һәрьяклап үсешкә омтылучы, социаль яктан җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыруга аерым игътибар бирелә.

– Белем багажы булу – бер хәл. Тик балаларның креатив фикерләвен үстерүдә төп рольләрне иҗат һәм мәдәният уйный. Милли бәйрәмнәрдә катнашып, халкыбызның мәдәнияте белән танышу, милли театрларга йөрү – күпкырлы шәхес тәрбияләүдә төп шартларның берничәсе. Кызганыч, бүгенге яшь буын мәдәният йортларына йөрергә гадәтләнмәгән, аларның кыйммәтләре башка. Әйтик, узган елның 1 сентябреннән бирле эшләп килүче «Пушкин картасы» проекты бу мәсьәләдә безнең өчен чын мәгънәсендә зур сынау булды. Ләкин системалы рәвештә башкарылган эш нәтиҗәсендә, Татарстан Россия буенча беренче позицияне яулады. Әлеге эшне «Пушкин картасы» куйган яшь чикләүләреннән бәйсез рәвештә дә дәвам итәргә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Баланың герое кем?

Совет утырышында Россия Дәүләт Думасының Мәдәният комитеты рәисе Елена Ямпольская да катнашты.

– Бүгенге вакыйгалар нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр, шул исәптән Россия мәдәният киңлегенең «яңаруы», һичшиксез, безгә файда китерәчәк. Бүген импортны үзебездәге товарларга алыштыру турында күп сөйләшәбез. Ләкин без, беренче чиратта, рухыбыз һәм кыйммәтләребезне үзгәртү турында уйларга тиеш, – диде ул. – Балаларыбыз милли геройлар, милли образлар тәрбиясендә үссен иде. Кешенең уй-фикерләрен ул укыган китаплар, ул караган фильм-спектакльләр генә формалаштырмый. Аңа үзе яшәгән мохит тә йогынты ясый. Әгәр дә балаларыбыз чит образлар, җырлар, геройлар, чит телләр чолгап алган мохиттә яши икән, без аларны чын патриот итеп тәрбияли алмаячакбыз. Алай гына да түгел, мондый мохиттә яшәгән кешенең күңелендә гармония булмаячак. Чөнки гармония үзеңә якын булган әйберләр чолгап алганда гына барлыкка килә ала. Безгә үз мәдәниятебезне мөмкин кадәр киңәйтү өстендә шактый хезмәт куярга туры киләчәк, чөнки без күз уңаеннан ычкындырган яклар җитәрлек. Милли мәдәният фестиваль-конкурслар белән генә чикләнергә, ә без үз мәдәниятебездән оялырга тиеш түгел.

«Постмодернизм сәләмәләре» һәм заманча сәнгать

Шуннан соң сүз Совет әгъзаларына бирелде. Сүз уңаеннан, Татарстанның мәдәният министры утырышта чыгыш ясамады, модератор ролен генә үтәде. Рөстәм Миңнеханов Ирада Әюповага: «Син сөйлә, аннан син сөйлә, дип, мин дә утыра алам. Сез бүгенге утырыш өчен уңайлы роль сайлагансыз», – дип, бераз «шелтә» дә белдерде.

Утырышта нинди мәсьәләләргә тукталдылар соң? Качалов театры директоры Александр Славутский беренчеләрдән булып чыгыш ясады. «Безнең театрның нигезен Островский, Гоголь, Пушкин, Шекспир, Мольер әсәрләре тәшкил итә. Ни өчен яшь тамашачы безгә классик әсәрләр карарга күпләп йөри? Чөнки аларның нигезендә – әхлак, намус, тәрбия мәсьәләләре. Постмодернизм сәләмәләре арасында күпме яшәргә була инде?» – диде ул.

«Алтын битлек», Муса Җәлил исемендәге һәм «Тантана» премияләре лауреаты Нурбәк Батулла исә Славутскийга да, башкаларга да заманча сәнгатьнең нигә кирәклеген аңлатып карады. «Барыбызның да кулында төймәсез телефоннар, тормышыбызның барлык өлкәләре диярлек үзгәреп тора. Без бит инде алдынгы төбәк буларак билгеле. Үзебезне чит илләрдә тәкъдим итәр өчен заманча сәнгатьтән дә яхшырагы юк, дип уйлыйм мин», – диде ул.

Ә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, уенын-чынын бергә кушып: «Александр Яковлевич, чит илләрдә безнең классик авторларны тыялар, әллә сез дә Шекспир, Мольерларны уйнамый торасыз мәллә?» – диде. Билгеле, Рөстәм Миңнеханов аның бу сүзләрен игътибарсыз калдырмады. «Без андый дәрәҗәгә төшәргә тиеш түгел», – диде ул. Ә Ркаил Зәйдулла исә бу фикеренең ирония генә булуын әйтте.

Ахыры 2 нче биттә >

Барысы да әзер

Татарстан язгы кыр эшләренә әзер. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров шулай дип белдерде. «Безнең өчен иң мөһиме – һава торышы. Узган елда корылык булу сәбәпле, якынча 50 миллиард сумлык продукцияне алмыйча калдык. Әлбәттә, предприятие җитәкчеләренә дә күп нәрсә бәйле», – диде ул #Татарстан-Онлайн программасы туры эфирында. Аның әйтүенчә, республикада чәчүлек мәйданнары 2,7 миллион гектар тәшкил итә. Алар узган елдагыча сакланып калган. Шул ук вакытта уҗым культуралары да әйбәт кышлаган. Министр әйтүенчә, ашламага да кытлык булмаячак. Ул тулысынча Россиядә җитештерелә. Декабрьдән май аена кадәр ашлама әзерләнә. Техникага килгәндә, чит илнекен Санкт-Петербург, Белоруссия тракторлары алыштырачак.

Марат Җәббаров сүзләренә караганда, орлык мәсьәләсе дә борчу тудырмый. Ашлык, кузак культуралары орлыклары белән 115 процентка тәэмин ителгән. Шикәр чөгендере, кукуруз, көнбагыш орлыгы әлегә 95 процент әзерлектә. Сүз уңаеннан, быел шикәр чөгендеренең чәчүлек мәйданы узган елгы дәрәҗәдә сакланып, 51,1 мең гектар тәшкил итәчәк.

Туристлар ашкына

Татарстан туристлар ташкыны артуны көтә. Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов әйтүенчә, чит илләр чикләренең ябык булуы һәм эчке туризмга ихтыяҗның нык артуына бәйле бу. Шулай итеп, республика сәяхәтчеләрнең иң яраткан урынына әйләнеп килә. Комитет рәисе сүзләренә караганда, туристлар саны турында әлегә төгәл генә мәгълүматлар юк. Аларның байтагы безгә килергә 1–2 көн кала гына кунакханә номерларын броньлый.

Шул ук вакытта кунакханәләрдән урыннар алу өчен бик күп заявка бирелгән инде. Сергей Иванов фикеренчә, ковидка каршы чикләүләрнең бетерелүе дә туристлар саны нык ишәюгә китерергә тиеш.

Сүз уңаеннан, моңа кадәр Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Туризм.РФ» генераль директоры белән туристлык инфраструктурасын үстерү турында документка кул куйды. Бу да республикага сәяхәтчеләр җәлеп итүгә зур этәргеч бирәчәк.

kzn.ru

Иркенгә чыгалар

Республиканың 615 IT-компаниясе Россия Цифрлы үсеш министрлыгында дәүләт аккредитациясе узган. Шуның 80е – IT-парк резидентлары. Хәзер алар федераль үзәктән ярдәм чаралары алу мөмкинлегенә ия. Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин шулай дип белдерде.

Әлеге компанияләрнең бер өлеше (206сы) әле быел гына аккредитацияләнгән. Мондый компанияләр 3 елга табышка салым түләүдән һәм төрле тикшерүләрдән азат ителәчәк. Моннан тыш 27 яшькә кадәрге хезмәткәрләр армия сафларына чакырылмаячак. Аларга шулай ук ташламалы ипотека бирелә. Шул ук вакытта IT-компанияләргә грант ярдәме, ташламалы кредитлар, хезмәткәрләрнең торак шартларын яхшыртуга акча, салым түләүдә өстенлекләр күздә тотыла.

Ярты бәясе кире кайта

Россия Хөкүмәте балаларга җәйге лагерьларга юллама бәясенең яртысын кире кайтару программасын озайткан. Премьер-министр Михаил Мишустин әйтүенчә, бу максатка 7,5 миллиард сум биреләчәк. Премьер сүзләренә караганда, быел кимендә 450 мең бала шушы мөмкинлектән файдалана алачак. Кешбэк программасы 30ыннан 31 мартка каршы төндә башлана. Лагерьга 1 майдан юл тотарга мөмкин булачак.

Программа кагыйдәләре буенча, балалар лагерена юллама «Мир» картасы белән сатып алынырга тиеш. Тотылган акчаның яртысы 5 көн эчендә картага кире кайтарыла (әмма 20 мең сумнан артык түгел). Бер балага кешбэклы юллама саны чикләнелмәгән.

Яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов әйтүенчә, Татарстанда 120дән артыграк балалар лагере бар. Аларның һәркайсына 1 майдан 1 сентябрьгә кадәр кешбэк буенча юллама сатып алырга мөмкин.

Вазгыять

Эшлим дисәң... табалар

Республиканың мәшгульлек үзәкләренә 9907 эшсез теркәлгән. «Работа в России» сайты алар өчен 55 мең вакансия тәкъдим итә. Бер кешегә 6 эш урыны бар дигән сүз бу. Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова «Татар-информ» агентлыгында узган очрашуда әнә шулай дип белдерде.

– Республикада халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү буенча өстәмә чаралар күрсәтелә башлый. Элек мәшгульлек үзәкләренә эшсез кешеләрчы генә мөрәҗәгать иткән булса, хәзер эштән китү куркынычы булган, тулы булмаган эш вакытына күчерелгән, эштән туктап торган хезмәткәрләр, хезмәт хакы түләнми торган ялга җибәрелгәннәр, банкротлыкка эләккән оешма эшчеләре, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче кешеләр дә ярдәм сорап килә ала, – ди министр. – Эшсезлек буенча түләнә торган пособиенең суммасы 12792 сумны тәшкил итә. Мәшгульлек үзәкләренә исәпкә баскан кешегә өч ай дәвамында шушы акча түләнә. Алдагы өч айда 5 мең сум бирелә. Аннан соңгы өч айда 1 мең 500 сум түләнә.

Министр аңлатканча, эш җитәрлек. Әгәр белгечлегенә туры килми икән, яңадан укыту мөмкинлеге дә бар. Оешмага бер эшчене укыту өчен 59 мең сум акча каралган. Бу максатка дәүләт 203 миллион сум акча бүлеп бирә. Үз эшен башлап җибәрүчеләргә дә ярдәм бар. Аларга бер тапкыр 145 мең сум акча бирәләр. Бу акчаны кире кайтарасы түгел. Шулай министрлык үз эшен башлаучыларга документларны рәсмиләштергәндә, бизнес план төзегәндә дә ярдәм кулы суза. Элек эш башлау өчен ике ел вакыт кирәк булса, хәзер моны бер ел эчендә башкарып чыгып була.

– Республикада «Демография» илкүләм проекты кысасында пенсия яшенә якынлашкан, декрет ялында булган, баласы бакчага йөргән эшсез әниләрне укыту күптәннән бар. Быел шулар янына эштән җибәрү куркынычы булган һәм 35 яшькә җитмәгән кешеләрне укыту да өстәлде. 5 мең 800 кеше һөнәр алыштырырга теләк белдерде инде. Дәүләт хисабыннан белем алырга теләгән кешеләр «Работа в России» сайтына теркәлеп, шунда гариза калдыра ала, – ди Эльмира Зарипова.

Югары уку йортын тәмамлап, тәҗрибәсе булмаганлыктан эш таба алмаучы яшьләрне хезмәт урыны белән тәэмин иткән оешмаларга да дәүләт ярдәме каралган. Эшлим дигән кешегә «Социаль контракт» та төзергә була. 2022 елның 1 мартыннан килешү төзегәндә эшсез дип табылган гаилә әгъзасының кереме исәпкә алынмаячак. Бу – дәүләт ярдәмен алу мөмкинлеге арта дигән сүз. Килешү җан башына уртача керемгә карап төзелә. Керем эшкә яраклы кеше өчен – 11 мең 724 сум, пенсионерлар өчен – 9 мең 250 сум, балалар өчен 10 мең 433 сумнан түбәнрәк булырга тиеш.

Министр быел кирәкле һөнәрләргә дә тукталды. Республикада техник торбаларны монтажлаучылар җитми. Шундый 1 мең 175 эшче кирәк. Газ белән эретеп ябыштыручылар, табиблар, машина йөртүчеләр, төрле өлкәләрдәге инженерлар, пешекчеләр җитми. Аларның уртача хезмәт хаклары 20–37 мең сумны тәшкил итә.

Эльмира Зарипова, илдәге вазгыятьтән чыгып, алдагы елларда кирәкле һөнәрләрне дә әйтте.

– Мәктәпне тәмамлаучылар нинди һөнәр сайлаячакларын хәл иткәндер инде. Татарстанда техник, азык-төлек өлкәсендә эшләүче инженер, химик, технолог, төзүче, фармацевт, медик, монтажчыларга кытлык булачак, – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

Сергей ЛАВРОВ, Россиянең тышкы эшләр министры:

Россиянең изоляцияләнүе турында бөтенләй сүз бармый. Гәрчә андый максат Көнбатыш илләре тарафыннан куелса да. Алай гына да түгел, без үзизоляциягә дә китәргә җыенмыйбыз. Җир йөзендә дусларыбыз, партнерларыбыз, барлык континентлардагы илләр белән эшләүче күпсанлы берләшмәләребез бар. Һәм без алар белән эшләүне дәвам итәчәкбез.

РОССИЯДӘ – ЭШ

Россиядә яшәүчеләрнең өчтән бере яңа эш урыны эзли икән. «Зарплата.ру» үзәге белгечләре ил халкының кайсы тармаклардан ешрак китүләре турында сорашкан.

КАЙСЫ ТАРМАКТАН КИТӘ?	
Банк тармагы	15%
Сәнәгать тармагы	12%
Хезмәт күрсәтү	11%
Сату, сәүдә	10%

НИ СӘБӘПЛЕ?	
Аз хезмәт хакы	40%
Кыскартылуга дучар булу	8%
Башка тармакка күчү	6%
Компания эшчәнлеген туктату	3%

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Татулык – байлык

Безне дөньядан аерымлап маташалар. Русчалатып әйткәндә, изоляциядә калдырып. Әлбәттә, бу бар дәүләтләр дә безгә арты белән борылды дигән сүз түгел. Җир шарында бүген ике йөзләп ил исәпләнә. Тик шунысы да хак: безгә каршы чикләүләр керткән кырыклап ил, ни кызганыч, Африка дәүләтләре түгел. Аларның күбесе – икътисади яктан алга киткән, моңарчы хәтсез өлкәләрдә безнең белән киң хезмәттәшлек алып барган мәмләкәтләр. Алар безгә җибәреп, сатып торганны – дарулардан башлап, авиалайнерларга кадәрле шактый киң ассортиментны хәзер каян, кемнән алырга? Икенче сорау: моңарчы Россия җитештергәнне, чималмы ул, әзер продукцияме, кемгә тәкъдим итәргә? Хәзер көн кадагына менгән, тиз генә җавап табу кыен булган сораулар болар. Әлбәттә, күпләр хуплаган импортны алыштыру дип аталучы икътисади сәясәт бар. Ул көчәячәк. Тик, тормыш күрсәткәнчә, читтә җитештерелгәнгә алмаш булдыру, экспортны саклап калу кебек үк, шома гына ерып чыга торган эш түгел.

Дөнья, андагы бәйләнешләр бүген глобаль. Җир йөзендә инде хәтсездән глобаль кооперация һәм хезмәт бүленеше дигән әйбер яшәп килә. Андый күренеш барлык илләр өчен дә үтә дә файдалы. Ул рациональ. Мәсәлән, кайсыдыр ил күптән велосипед җитештерә ди. Ул җиһаз дигәндә фирма инде күптән азау тешен ярган. Шуңа продукция ышанычлы һәм дә арзан. Башкаларга аны шул илдән, шул заводтан сатып алу кулай һәм отышлы. Әмма матур гына бер көнне ул товарны сиңа сатмый башладылар ди. Кемдер әйтер, исең киткән икән, велосипед нәрсә инде ул, теләгәндә аны теләсә кем ясый, дияр. Ясый ясавын, тик син җитештерә башлаган ике тәгәрмәчле ул транспорт өч, хәтта биш бәясенә төшә дә куя. Ничекме? Сәбәпләре хәтсез. Аларны яхшы аңлау өчен җитештерү сферасында аз булса да эшләп алу кирәктер. Кыйммәтләнә, чөнки, беренчедән, аны чыгара башлаганчы күп хәстәрлек күрәсе – сызым, технологик документация эшләүдән башлап, тиешле җиһазлар, станоклар сатып алу, персонал әзерләү, материал, комплектлаучы детальләр юнәтүгә кадәр. Барысы белән дә элемтәләр җайлыйсы, логистика булдырасы. Бу гамәлләр җитештерүне әзерләү (подготовка производства) дип атала. Үзен хөрмәт иткән заводта, гадәттә, бары шул эш – яңа продукцияне үзләштерү өчен генә җаваплы кеше – директорның яисә баш инженерның берәр урынбасары була.

Хуш, барысын да җайлап, велосипедны чыгара да башладың ди. Ул теге, элек читтән кергән транспорт чарасы кебек ышанычлы, кулланучының барлык таләпләренә дә җавап бирә торган булачакмы? «Едва ли». Брендка әйләнәчәкме? Шикле, чөнки син әле аны ясый гына башладың, данлыклы марка булу өчен вакыт кирәк. Җиде кат тирләү кирәк. Продукция әле кимчелекле, ул эчке базарда гына сатыла. Дустанә илләр дә аңа кызыкмый, брендлы товар ягына карый. Шуңа серия – җитештерү күләме дә бик чикле. Менә шушы хәлләр бәяне арттыручы икенче һәм дә төп сәбәп тә инде.

Нәкъ шуңа күрә үзкыйммәте югары, сыйфаты түбәнне ясап, яңадан велосипед уйлап табып ятучылар бүгенге глобаль икътисадта юк. Дөньяви хезмәт бүленешенең кагыйдәләре шундый, син дә, үз чиратыңда, мәсәлән, бик оста һәм арзанлы итеп аяк киеме җитештерәсең. Барысы да, рәхмәт укып, аны синнән ала. Ягъни син – миңа, мин – сиңа. Шушы механизм, схема – бар илләрдә дә тормыш сыйфатын үстереп, татулыкны арттырып торучы фактор. Схема эшләмәү, булмау артыгын көчәнүгә, кирәкмәгән чыгымнарга, икътисадның нәтиҗәле булмавына китерә. Ә инде велосипед түгел, зур тизлектә чаба торган электровоз яисә авиалайнер ясарга алынсаң? Андый чакта кирәкмәгән чыгымнар күләме бермә-бер арта.

Авиалайнерлар дигәндә, әле дә ярый бездә совет заманыннан калган тәҗрибә, традицияләр бар. Белгечләр дә юк түгел. Казанда Ту-214 пассажир самолетын җитештерергә тотынганда 1990 нчы елларда ук булдырылган сызым, документация, комплектлаучы детальләрдән бигрәк, лайнерны җыю тәҗрибәсе дә чыгымнарны киметер дип өметләник. Керосинны күп «ашаса», заманча булмаса да, ул үзебезнең очкыч булачак. Чөнки авиапассажирлар ташуда вазгыять бик четерекле бүген. 1300дән артып киткән төрле зурлыктагы лайнерларның 78ен чит илләр конфискацияләп үзендә калдырды. Ярты меңләп самолет лизингта булып, аларның хуҗалары түләнеп бетмәгән акчаны кичекмәстән кайтаруны таләп итә. Ә ул – 20 млрд доллар дигән сүз. Икенче күңелсез факт – илдәге самолет паркы читтә эшләнгән Боинг, Айрбас (Airbus) лайнерларыннан торганлыктан, аларга запас частьларны каян аласы, ничек итеп тиешенчә карап тотасы? Сорау әлегә ачык кала…

Чикләүләр шартларында инде тарихка күчкән СССР тәҗрибәсен, аның нәтиҗәләрен искә төшерү дә урынлыдыр. Колачлы санкцияләр булмаса да, ил «тимер чаршау» артында – изоляциядән бигрәк үзизоляциядә гомер сөрде. 71 ел эчендә уңышлар да булмады түгел. Ә инде авырлыклар барыннан да бигрәк әлеге дә баягы шул дөньяви хезмәт бүленешендә катнашмау сәбәпле яралды. Социализмның халыкны тинтерәтмәгән соңгы ике-өч дистә елын гына искә төшерик. Яхшы автомобильләр җитештерергә тәки өйрәнә алмадык. Чит ил машинасы – иномарка һәр совет кешесенең тормышка ашмас хыялы булды. Машина гына түгел, хәтта читтә тегелгән джинсы чалбар да әллә нәрсә иде. Ә электроника, башка күп төрле куллану товарлары? Электроника дигәннән. Без – ул өлкәгә кагылышы булган кавем, студент елларында ук: «Яшәсен совет микросхемалары – дөньяда иң зур микросхемалар», – дип шаярыша идек. Алар ясалды, тик заман таләпләренә җавап бирмәде. Хәзер бөтенләй дә шаяртып булмый. Чөнки электрон компонентлар җитештерү юк хисабында. Яхшы итеп ясый белмәгәч, сатып алу хәерле, дидек. Моңарчы шулай булды. Чипларны безгә Кытай, Япония белән Көньяк Корея, башкалар бирде. Кытай хәзер дә буш итмәс, тик менә калганнар… Япония белән Кореяның Россиядәге автозаводлары язмышы, аларга запас частьлар – бу өлкәдә дә әлегә билгесезлек.

Дөнья глобаль һәм дә бик мобиль. Ябылып яшәү пандемияләр вакытында гына файдалы дияр идең, анда да тулысынча бикләнәм, качам димә. Рәхәт, проблемаларсыз яшисе килгәндә бөтен дөнья белән икътисади элемтәләр булу, аларның тулы канлылыгы зарур. Татулык – байлык, дип юкка гына әйтмиләр.

ТӘКЪДИМ БАРДА ФАЙДАСЫН КҮР

Сулар чистарак, нефтькә кушылмалар үзебездән булачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Татнефтехиминвест-холдинг» җәмгыяте Директорлар советы утырышында тормыш-көнкүрешкә генә түгел, ил икътисадына ярдәм итәрдәй проектлар белән танышты.

tatarstan.ru

Әйтик, «Нэфис Косметикс» җәмгыяте генераль директоры Динә Лаврикова сүзләренчә, хәзерге вакытта чимал белән тәэмин итү мәсьәләсе кискен калкып чыкты. Россиядә сыек савыт-саба юу чараларын җитештерү өчен кирәк ул. Мәсәлән, порошок рәвешендәге юу чараларын җитештерүдә ай саен 600 тонна альфа-олефин кулланылган, анысын АКШтан кайтара торган булганнар. Башка ихтыяҗлар өчен натрий алкилбензолсульфонаты кирәк. Хәзер инде алмашны «Түбән Кама Нефтехим» һәм «ТАНЕКО» кысасында эзләргә тәкъдим ителде. Ике компания дә икътисад тотрыклылыгы өчен бу проектларны сынап карарга әзер булуларын әйтте. Ә Татарстан Президенты исә бу сорауны федераль дәрәҗәдә күтәрүдә ярдәм күрсәтергә вәгъдә итте.

Екатеринбургның «УНИХИМ» җәмгыяте вәкиле Илья Романов суны чистарак итү мәсьәләсенә тукталды. Хлор диоксиды ярдәмендә эчә торган һәм агынты суларны чистарту ысулы уйлап табылган. Бу сыек хлор куллануга караганда күпкә нәтиҗәлерәк тә икән.

«Эко-транс» җәмгыятенең фәнни төркем җитәкчесе Наил Мириханов нефть һәм нефть продуктларына өстәлә торган яңа күпфункцияле кушылма хакында сөйләде. Ул Россиядәге чималлардан гына җитештерелә. Димәк, чит илнекенә алмаш бар дигән сүз. Моңа өстәп, кушылманы әзерләгәндә спирт һәм башка зарарлы химик матдәләр файдаланылмый дип ышандырды фәнни төркем җитәкчесе. Кушылма – үтәкүренмәле, двигательләрне коррозия һәм тиз тузудан саклый. Рөстәм Миңнеханов аны «ТАНЕКО» лабораторияләрендә сынап карарга һәм «КамАЗ»да да файдаланырга кушты.

КФУның Исәпләү математикасы һәм мәгълүмат технологияләре институты директоры Дмитрий Чиркин машина һәм агрегатларның нәтиҗәлелеген контрольдә тоту өчен комплекс турында сөйләде. Махсус виброанализ системасы җайланмаларның эчке җитешсезлекләре хакында хәбәр бирергә сәләтле. Рөстәм Миңнеханов әлеге проектны нефть һәм энергетика тармагы вәкилләренә өйрәнергә кушты. «Тикшереп тору мөһим. Бу төзекләндерү өчен китәчәк вакытны янда калдырачак», – диде Президент.

ЛИЦЕЙДА – ПАРЛАМЕНТ ДӘРЕСЕ

Казанның Лобачевский исемендәге лицеенда «Мин – Гражданин. Минем хокукларым һәм девизларым» дигән парламент дәресе узды. Анда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин эксперт сыйфатында катнашты.

Парламент башлыгы укучылар белән аралашты, Татарстан Конституциясенең (быел 30 еллыгы билгеләп үтеләчәк) ничек кабул ителүе, республиканың Төп Законында нинди хокукларның гарантияләнүе турында сөйләп үтте.

Дәрестә 11 нче сыйныф укучылары үзләренең хокуклары һәм бурычлары буенча фикер алышты, тарихи, мәдәни мирасны саклау мәсьәләләренә аерым тукталып узды. Лицейның 6–10 нчы сыйныфларында укучылар видеоэлемтә аша дәрестә катнашты.

«Конституциябез катлаулы, авыр чорда кабул ителде, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин, Төп Закон буенча эшчәнлекне искә төшереп. – Республикага зур дәүләттә үзенең урынын табарга, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны сакларга, алга таба үсү мәсьәләләрен хәл итәргә туры килде. Иң мөһиме – күпмилләтле халкыбызны берләштерүгә ирешелде».

Парламент башлыгы Конституция нигезләмәләренең биш айдан артыграк вакыт дәвамында эшләнүе турында сөйләп үтте. 1992 елның 6 ноябрендәге тарихи вакыйгага кадәр Конституцион комиссия бик катлаулы эш алып барган. Аңа күренекле галимнәр, сәясәтче, икътисадчылар һәм хокук белгечләре кергән. Конституцияне кабул итү дә җиңел генә булмаган. «Без халыкларның үзбилгеләнешкә, сүз ирегенә хокуклы булуына таянып эш иттек», – дип басым ясап әйтте Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент дәресе алдыннан Фәрит Мөхәммәтшин лицей директоры Елена Скобельцина озатуында уку йортының музейлары белән танышты, Мария хатын-кызлар гимназиясенә, Хәрби-һава көчләренең Казан 9 нчы махсус мәктәбе, Декабристлар исемендәге 6 нчы Совет урта мәктәбенә багышланган экспозицияләрне карады. Бу уку йортлары төрле елларда лицейның тарихи бинасында эшләгән. Анда инде 150 елдан артыграк вакыт дәвамында лаеклы алмаш әзерлиләр.

Дәүләт Советы, Дәүләт Думасы, җирле үзидарә органнары депутатлары катнашындагы парламент дәресләре (быел Конституция кабул итүгә 30 ел тулуга багышланды) февраль – март айлары дәвамында барлык мәктәпләрдә узды. 1 февральдән парламент дәресе кысасында иҗади хезмәтләр бәйгеләре үткәрелә. Җиңүчеләр апрель аенда Дәүләт Советында бүләкләнәчәк.

Соңламыйк...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Режиссерсыз нишләрбез?

«Әкият» курчак театры директоры Илгиз Зәйни татар театрларына режиссерларсыз калу куркынычы янавын әйтте. «Бүген республикада 60 яшькә якынлашкан – дүрт-биш, 40–60 яшьләр арасында – ике, 30–40 яшьлек 10лап режиссер бар. Ә бездән яшьрәкләр арасында мин бер генә режиссерны беләм. Татар телендә эшли алучылар турында сүзем. Әлегә бу проблеманы без сизмибез, чөнки безнең эшләп торган чак, бездән өлкәннәр дә бар. Ләкин режиссер режиссер булып җитлексен өчен, ул кешене менә бүген укырга кертсәк тә, аңа ким дигәндә 10 еллап вакыт кирәк. Татар театры – ул үзе зур традиция. Бу традиция өзелсә, аны ялгавы кыен булачак. Бүген Татарстанда профессиональ режиссерлар әзерли торган уку йорты юк. Бу мәсьәләне хәзер хәл итмәсәк, үкенечле булачак», – диде ул.

Казан мәдәният институты ректоры Роза Әхмәдиева исә Илгиз әфәнде белән килешмәде һәм үзләренең режиссерлар әзерләп чыгаруын әйтте. «Ләкин сездә халык театры режиссерлары әзерлиләр. Бу – бөтенләй башка юнәлеш», – дип җавап бирде аңа Зәйни. Ул шулай ук әлеге проблеманы хәл итү юлларын да атады. Рөстәм Миңнеханов исә бу мәсьәләдә ярдәм күрсәтергә вәгъдә бирде.

Кинорежиссер Алексей Барыкин исә кинотеатрлар репертуарының «бушап» калуы Россия кинематографиясе өчен уңай булуын искәртте.

…Мәдәният һәм сәнгать советы утырышында иң еш телгә алынган сүзләр «яшьләр» һәм «балалар» булгандыр. Киләчәкнең нинди булуын алдан фаразлавы кыен, ләкин без үзебездән соңгы буынга таянырдай терәүләр булдырырга тиеш. Иң әһәмиятлеләренең берсе – мәдәният. Бәлки, күп мәсьәләләрдә без инде соңга калганбыздыр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та шулай ди. «Безне алда әллә нинди авырлыклар көтәргә мөмкин – без әзер булырга тиеш», – диде ул, утырышка йомгак ясап.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сөтлебикә акча китерә

ШӘХСИ ХУҖАЛЫКЛАР НИНДИ ЯРДӘМГӘ ӨМЕТЛӘНӘ АЛА?

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы ел саен сыер тотучы хуҗалыклар өчен субсидияләрне августта бүлеп бирә иде. Быел бу ярдәмне иртәрәк – апрель һәм май айларында алачаклар. Бу хакта журналистларга авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ришат Хәбипов хәбәр итте.

Аның сүзләренчә, әлеге ярдәм чарасы быел да, узган елдагы шикелле үк, «Минем субсидияләр» платформасы аша эшләнәчәк. Шулай ук халык әлеге сораулар буенча авыл Советына да мөрәҗәгать итә ала.

– Бу системада теркәлгән кеше шәхси бите аша субсидия алыр өчен гариза тапшыра. Авылда 900 мең тирәсе халык яши. Ләкин аларның барысы авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнми. Кемнең ничә терлек тотуын күреп, белеп торабыз, – диде Ришат Хәбипов.

Узган ел 35 меңнән артык гариза тапшырылган булган. Субсидия күләменә килгәндә, үзгәрешләр юк. Бер сыер тотучыга – 2000 сум, икене асраучыга – һәр сыерга 3000әр сум, өч һәм аннан да күбрәкне асраучыларга сыер башына 4000 сум акча каралган. Быел әлеге ярдәм өчен бюджетта 350 млн сум каралган. Моннан тыш, ветеринария чыгымнары өчен һәр сыерга 300 сум акча бирелә.

Билгеле булганча, республикада тана сатып алучыларга матди ярдәм чарасы каралган. Моңа кадәр Ришат Хәбипов татар эшмәкәрләре белән очрашкан вакытта быел әлеге субсидия күләме ике тапкыр арттырылганлыгын әйткән иде.

– Узган ел хуҗалыктан алынган танага – 30 мең сум субсидия бирелсә, быел аның күләме 60 меңгә кадәр җитте. Токымлы тана өчен моңа кадәр 40 мең сум каралган иде, быел аны 70 меңгә җиткердек, – диде Ришат Хәбипов Россиянең татар авыллары эшмәкәрләре белән очрашуда.

Субсидия күләме арту таналар кыйммәтләнү белән бәйле. Министр урынбасары сүзләренчә, бүгенгә яхшы тана алу өчен 120–150 мең сум акча кирәк. Шәхси хуҗалыгында сыерлар санын арттырырга теләгән кешеләргә абзар салу өчен дә субсидия күләме быел сизелерлек арткан.

– 2–3 сыеры булып, аларның санын бишкә җиткерергә уйлаган кеше абзар, мини-ферма төзү өчен моңа кадәр 200 мең сум субсидия ала иде. Без быел аның суммасын 300 мең сумга җиткердек. Сыерлар санын сигез башка җиткерү бурычын куйган кеше өчен субсидия күләме 400 меңнән 600 меңгә кадәр күтәрелде, – диде Ришат Хәбипов.

Фермерларга ярдәм чараларына килгәндә, алар берничә төрле грант ота ала. Акчаның 60 проценты – федераль, 40 проценты республика бюджетыннан бирелә. Татарстанда фермерлар, кооперативлар өчен «Агропрогресс», «Гаилә фермаларын үстерү», «Авыл хуҗалыгы кооперативларының матди-техник базаларын үстерү», «Агростартап» программалары эшли.

– Бәяләр үсүен исәптә тотканда, әлеге грантларга бүлеп бирелгән акча җитәрлек түгел дип саныйбыз. Ләкин шул ук вакытта катнашырга теләүчеләр елдан-ел арта. Моңа кадәр авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә теләүчеләр арасында бераз сабыр итәргә карар кылучылар да бар. Чөнки безнең тармакта югалтулар да бар. Икмәк өчен һәрвакыт көрәш бара. Быел исә без зур уңыш алуга өметләнәбез, – диде Ришат Хәбипов.

Зөһрә САДЫЙКОВА

СӨЙЛӘШҮ ДӘ, ӘНДӘШҮ ДӘ КУРКЫНЫЧ

Акчам булмагач, алдамаслар, дип тынычланма! Мошенник, уйласа, сезнең исемгә кредит рәсмиләштереп булса да төп башына утыртачак. Хокук сакчылары халыкны шулай дип кисәтә.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының җинаятьчеләрне эзләү идарәсе башлыгы урынбасары Рәмис Газыймов сүзләренә караганда, телефон аша кылынган җинаятьләрнең 33–34 процентын нәкъ менә шушы төр мошенниклык очраклары тәшкил итә. «Банк хезмәткәре беркайчан да клиентка турыдан-туры үзе шалтыратмаячак. Бу – мошенниклар алымы. Клиентның исәп-хисап счеты белән бәйле шикле операцияләр булган очракта да банк аларны автомат рәвештә туктатачак», – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда.

Әлеге ысулны үз итүче мошенниклар, гадәттә, үзләре генә эш итми. Шуңа күрә быелдан башлап хокук сакчылары аларның арадашчыларын да җинаять җаваплылыгына тарта башлаган. Элегрәк курьер булып еш кына таксистлар йөргән булса, соңгы арада алар бу эштән баш тарта икән. Шуңа күрә бүген җинаятьчеләр үзләренә ярдәмчене, нигездә, «Телеграм» каналы аша таба. Мошенникларга ярдәм итүче арадашчылар арасында хәзер яшьләр, хәтта балигъ булмаганнар да очрый. Шуңа күрә нәрсәнедер илтеп биргән, алып кайткан өчен бик зур акча вәгъдә итсәләр, шикләнергә кирәк, ди белгечләр.

Һәр нәрсәдән отып калырга күнеккән мошенниклар килеп туган вазгыятьтән дә файдаланып калырга тырыша. Әле берничә көн элек хокук сакчылары Чистайда яшәүче 80 яшьлек әбине төп башына утырткан ике хатын-кызны тоткарлаган. «Акча алышыначак. Шуңа күрә булган акчагызны саклап калырга ярдәм итәсебез килә», – дигән булып, әбинең соңгы акчасына кадәр алып чыгып киткән алар.

Рәсми саннардан күренгәнчә, соңгы биш елда республикада киберҗинаятьләр саны ун тапкыр арткан. Чагыштыру өчен: 2017 елда Татарстанда шундый 4 мең очрак теркәлгән булса, узган ел бу сан 14 меңгә җиткән. Дөрес, быелның гыйнвар – февраль айларында республикада киберҗинаятьләр саны шактый кимегән. Әйтик, ике ай эчендә банк карталарыннан акча урлау очраклары гына да 200 җинаятькә азрак теркәлгән.

Рәмис Газыймов сүзләренә караганда, телефон аша эш итүче җинаятьчеләрнең күбесе – чит төбәктә яшәүчеләр. Узган ел аларның эзенә төшү өчен чит төбәкләргә 600дән артык командировка оештырырга туры килгән. Үзебездә яшәп, алдап ятучыларны да аулыйлар, билгеле. Әле декабрьдә генә Казанның Вознесение бистәсендә кырыгалдарларның колл-үзәген тапканнар. Корбаннарын, сатып алынган дару һәм БАДлар өчен компенсация алырга ярдәм итәбез, дип алдаган алар. Шул рәвешле алар халыкны 12 миллион сумга төп башына утырткан.

«Мошенниклар бушлай игълан сайтларын да ярата. Әле күптән түгел генә шуларның берсе кулга алынды. Берничә көн элек кенә машинасын сатып җибәргән ир-атка шалтыратып, үзен машинаны сатып алган кеше дип таныштырып: «Машинагызда бер көн дә йөри алмадым – ватылды, ремонтка акча бирмәсәгез, аны кире кайтарам», – дип яный башлаган. Машинаның элекке хуҗасы исә, эшне зурга җибәрергә теләмичә, ул сораган акчаны күчергән. Тикшерү барышында мошенникның Самара кешесе икәнлеге ачыкланды. Берничә ел элек иреккә чыккан әлеге ир-ат рәхәтләнеп тавышын үзгәртә, хәтта хатын-кыз булып та сөйләшә ала», – ди Рәмис Газыймов.

Мошенникларның бик оста психолог булулары күптән яңалык түгел анысы. Хокук сакчылары тикшерү барышында кырыгалдарларның әйберләре арасында кешедә ышаныч тудырырга, дөрес итеп сөйләшергә өйрәтә торган күпсанлы психологик китаплар да тапкан.

Кирәк әйберне интернет аша – онлайн рәвештә генә сатып алырга күнеккән кешеләр арасында да алданучылар күп. Шуңа күрә белгечләр аларга маркетплейс, ышанычлы оешмалардан гына заказ бирергә киңәш итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Арзан бәягә кызыгып, шикле оешмадан онлайн рәвештә әйбер сатып алырга кирәкми. Заказ биргәч, буш посылка килде яки бөтенләй килмәде, дип зарланып мөрәҗәгать итүчеләр күп. Бүген теркәлгән киберҗинаятьләрнең 18 проценты нәкъ менә шушы төркемгә туры килә», – ди Рәмис Газыймов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ ҮЗ ПРЕМИЯСЕН БУЛДЫРГАН

Балтач районының Чепья авылында яшәүче, 29 мартта 95 яшен тутыручы Бөек Ватан сугышы ветераны Гарифҗан Галиев үз исемендәге премия булдырган. Әлеге премия районның мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә яшь буынны тәрбияләүдә зур өлеш керткән 45 яшькә кадәрге хезмәткәрләргә биреләчәк.

Гарифҗан Галиев – республика күләмендә билгеле, олы хөрмәткә лаек шәхес. Ул оештырган «Халыклар дуслыгы» музее үзе генә ни тора! Тарих укытучысы буларак, Гарифҗан Галиев 1965 елның 1 маенда, Җиңүнең 20 еллыгы уңаеннан мәктәптә тарих почмагы оештыра. Укытучылары кул астында мәктәп укучылары фронт хатларын, документларны барлый, туплый башлыйлар. Музей фондында тупланган әйберләрнең 97 проценты – Чепья урта мәктәбендә белем алган 42 авыл малай һәм кызларының хезмәте, ди Гарифҗан Галиев. Музей көннән-көн зурая. Мәктәп кысасыннан үсеп чыгып, аерым бинага күчә. 1989 елның маеннан ул инде Татарстан Республикасының Милли музее филиалы булып эшли башлый. «57 ел эчендә без 22 меңнән артык экспонат җыйдык. Безнең югары дәрәҗәбезне хәзер Казан да, Мәскәү дә таный. Музей дөньяның 26 иленнән кунакларны кабул итте, 3 илнең илчесе бездә булып китте», – дип горурланып сөйли Гарифҗан ага.

57 ел инде Гарифҗан Галиев – музейның алыштыргысыз директоры. Шөкер, хәзерге көндә дә сафта, әле дә экскурсияләр алып бара. Һәрбер экспонат турында ул сәгатьләр буе сөйли алыр иде. Аларның кыйммәтен аннан да ныграк аңлаган кеше бармы икән?! Гарифҗан Галиевне райондашлары иганәче буларак та беләләр. Ул туган авылы Каенсарда шәхси акчасына авылдашлары хөрмәтенә һәйкәл салдырган кеше дә әле. Күлне чистартып, авылдашларын сулы итүче дә. Инде менә тагын нинди зур яңалык: ул үз исемендәге премиясен булдырган. Сугыш кырында үлем белән күзгә-күз очрашкан солдат гомеренең һәр көнен халкына, иленә хезмәт итеп үткәрә. Ничек кенә пафослы яңгырамасын, мондый кеше тагын бармы икән?! Бөек Ватан сугышын да, рус-япон сугышын да күрергә туры килә аңа. 1944 елның август аенда 17 яшьлек егет үз теләге белән Кызыл армия сафларына баса. Бөек Ватан сугышында Ил-2 штурм самолетында атучы һава радисты буларак катнаша. «Унҗиде яшем тулганчы мине хәрби училищега алдылар, бер елдан инде һава флотында Ил-2, Ил-10 маркалы самолетларда укчы-радист булып хезмәт итә идем инде», – дип искә ала ул. Алар «оча торган танклар» дип йөртелүче, 6,5 тонналы бронялы авыр техника, артык биек күтәрелмичә, күперләр, дзотларны юкка чыгару, танкларга каршы сугышта кулланыла торган техникалар иде. Алар ике экипажлы гына: очучы һәм солдат.

– Безгә ШКАС пулемётлары һәм авиабомбалар белән коралланып, Мукден, Харбин шәһәрләре өстендә барган һава сугышларында һәм Порт-Артурны алуда катнашырга туры килде, – дип сөйли ветеран. Шушы канлы бәрелештә Гарифҗан ага бик каты яралана. Очкан вакытта аларның моторлары эштән чыга. «Ничек җиргә төшкәнемне хәтерләмим, госпитальгә эләккәнмен. Кызганычка, безнең очучы һәлак булган», – дип уйлары белән шул дәһшәтле көннәргә кайтып килгәндәй булды ветеран.

Гарифҗан ага – үткәннәрнең тере шаһиты. 95 яшьлек юбилей көннәрендә аңа ныклы сәламәтлек телибез.

Гөлназ МИНҺАҖЕВА.
Балтач районы Чепья авылы

БӘЙДӘН ЫЧКЫНДЫРМЫЙЛАР

1861 елның март аенда крепостное право юкка чыгарылып, крестьяннар ireккә чыга. Мондый саллы реформалар, гадәттә, шактый гына болганышлар хасил итеп, бер чор белән икенчесен алыштыра. Казан губернасында мондый үзгәрешләр яшәешкә ничегрәк тәэсир иткән? Тормыш арбасы кайсы якка таба тәгәрәгән? Бер яктан караганда, крестьяннар өчен бу бик файдалы да булган кебек. Шулай булгач, ни өчен әле монда, әле тегендә фетнәләр күтәрелеп торган? Шушы сорауларга җавап табу йөзеннән, тарих битләренә күз салыйк әле.

Астан килгәнне көтәсе түгел

Феодаль системаның кризиска килеп керүен һәм крестьяннарның баш күтәрүе ешайганын аңлаган император Александр II, гәрчә моңа дворяннарның, түрәләрнең күп өлеше каршы булса да: «Крепостное правоның астан юкка чыгарылганын көтеп утырганчы, өстән басым ясау яхшырак булыр», – дигән фикергә килә. Реформаны әзерләү өчен Крестьян мәсьәләсе буенча яшерен комитет төзелә. Шул исәптән 50 губернадагы дворяннар комитеты крестьяннарны азат итү проектларын эшли. Казан губернаторы Козлянинов та бу эшкә рөхсәт ала.

1859 елның апреленә «Казан губернасында алпавыт крестьяннарының хәлен яхшырту турында» проект эшләнә. Әмма, аңлашыла ки, кулдагы байлыкны бирергә беркем дә ашкынып тормый. Документта «алпавытларның җиргә милек хокуклары кагылгысыз кала», «урманнар алпавытлар кулында кала» дип күрсәтелә. Алпавытлар барлык җирне үз милекләре итеп игълан итә, бер өлешен генә акчага яки натуралата тапшырылган әйберләр бәрабәренә өләшергә карар кылына.

Бер кешегә 1,75 дисәтинә җир бүлеп бирелә, шул ук вакытта, әйтергә кирәк, җан саклап калу өчен 6–8 дисәтинә кирәк була. Бер дисәтинә җир өчен комитет тарафыннан салым 4 сум 50 тиен көмеш күләмендә билгеләнә. Өстәвенә крестьяннарга җирне арендага бирергә, үз биләмәләрендә урман яки күл булган очракта, агач кисәргә, балык тотарга ярамый. Бүлеп бирелгән биләмәне дә алпавытның теләсә кайсы вакыт алыштырырга хокукы була.

Казан комитеты проекты буенча, бәйлелектән котылу өчен ир-атлар – 120 сум, хатын-кызлар 60 сум акча түләргә тиеш була. Кыскасы, бер нәрсәне дә күздән ычкындырмас өчен, кулдан килгәннең барысы да эшләнә. Чөнки алпавытлар өчен крестьяннарның бәйле булып калуы бик уңайлы була. Мондый проектка хәтта губернатор үзе дә каршы килә, крестьяннар арасында фетнәләр башланмасын дип курка. Әмма, тулаем алганда, әлеге проектта законга каршы килә торган әйбер «тапмыйлар».

Крестьяннарны кабалага кертүнең тагын бер юлы уйлап табыла. Бу – имеш, алпавыт биләмәләрен авыллардан чистарту. Йортны ташлап чыгып китә алмыйсың. Ахыр чиктә буйсынырга туры килә. Шулай итеп, элеккеге крепостной крестьяннар белән идарә итү өчен яңа аппарат төзелә. Хуҗалыкларын авыл сходына берләштереп, староста сайлыйлар. Сходлар волостька берләшә. Аның үз идарәсе һәм суды була. Шулай итеп, крестьяннарның бернинди ирегe дә калмый, алар турыдан-туры патша хакимиятенә бәйле булып калалар.

Дәүләт крестьяннары

Капитализмга бару юлында реформалар бертуктаусыз дәвам итә. 1866 елда дәүләт крестьяннарына да чират җитә. Тора-бара алар хокуклары буенча крепостной крестьяннарга тигезләшеп калалар. Дөрес, аларның биләмәләре алпавыт крестьяннарына караганда шактый зур – 4,7 дисәтинәдән алып 6,4кә кадәр була. 1866 елгы реформада халыкны милләт буенча да аералар: мәсәлән, русларга җан башына уртача 6,4 дисәтинә җир бирелсә, бу сан мордва белән удмуртларда – 6; мариларда – 5,7; чуашларда – 5; татарларда – 4,7. Өстәвенә Казан губернасының көнчыгыш һәм төньяк өязләрендә рус булмаган дәүләт крестьяннарыннан урманнарны тартып алалар. Әмма ничек кенә булмасын, дәүләт крестьяннары помещикларныкына караганда яхшырак хәлдә яши, чөнки җирләре күбрәк, салымнары азрак була.

Үзгәрешләр

Крестьяннар бәйлелектән котыла алмаса да, тормышлары яхшырмаса да, мондый үзгәрешләр илдә капитализм коруга юл ача. 1860–1870 нче елларда Россиядә земство, суд, шәһәр, цензура, финанс реформалары үткәрелә. Земство учреждениеләре беренчеләрдән булып Казан губернасында гамәлгә куела. Анда үзидарә органнары пәйда була. Башта алар дәүләт эшенә кысылмыйлар, хуҗалык эшләрен алып баралар. Әмма сайлау нәтиҗәсендә земство әгъзалары күбрәк дворяннар булган саен, алар җәһәт кенә хакимияткә үрлиләр. Нәтиҗәдә шәһәр Думалары, шәһәр идарәләре төзелә. Аңлашыла ки, Думага күбрәк бай кешеләр сайлана.

Иң прогрессив дип саналган реформаларның берсе – суд реформасы. Яңа устав нигезендә төрле катлау кешеләрнең закон алдындагы хокуклары тигезләшә.

Халыкара хәлләрнең киеренке торуы хәрби өлкәне дә үзгәртеп кору кирәклеген искәртә. 20 яшькә җиткән һәр ир-ат хәрби хезмәткә алына башлый. 25 еллык срок коры җирдә хезмәт итүчеләргә – 6 елга, флоттагыларга 7 елга кала. 1864 елда «Хәрби округлар турында» нигезләмә раслана. Ил территориясе 15 округка бүленә. Бу исемлектә Казан да була. Казан хәрби округы үз эченә Идел буен һәм Уралны ала. Армия яңа хәрби техника белән коралланa башлый. 1877–1878 еллардагы рус-төрек сугышында бу үзгәрешләрнең файдасы бик ачык сизелә.

Фетнәләр

Үзгәрешләр шактый гына уңышлар китерсә дә, үзләренең «ярык тагарак» янында утырып калулары белән күп крестьяннар килешми. Реформа үткәрелгәннән соң баштагы биш айда гына да 1340 җирдә крестьяннар баш күтәрә. Иң күп фетнә Казан губернасында була. Өч ай эчендә монда 75 крестьяннар хәрәкәте теркәлгән. Бу хәрәкәт тора-бара восстаниегә әйләнеп, аның үзәге Спас өязенең Бизнә авылында була. Алар Александр II «Нигезләмә...»сендәге «яңалыклар» белән килешә алмыйлар, бу хакта югарыда торучыларга җиткерәләр. Әмма аларны беркем дә тыңларга теләми. Шунда алар авылдашлары Антон Петров янына киләләр һәм хәлне аңлатып бирүен сорыйлар. Ул аларга үзләренең ирекле булуларын җиткерә, помещикларны тыңламаска өйрәтә. Бу сүзләр бик тиз тарала. Крестьяннар салым түләүдән баш тарталар, алпавыт урманнарын кисәләр, хайваннарын куалап китәләр. Спас өязендә генә дә бу фетнәгә 75 авыл кушыла. Антон Петровның абруе көннән-көн үсә. Ул тирә-як авылларга үзенең теләктәшләрен җибәрә, Бизнәгә җыелырга куша. Алпавытларның күбесе, куркып, Казанга кача.

Фетнәне бастыру өчен, Спас өязенә генерал-майор Апраксин юлга чыга. Бизнәгә килгәч, Антон Петровны бирүләрен таләп итә. Крестьяннар ризалашмый. Апраксин коралсыз төркемгә атарга боера. Фетнә бастырыла. Күп крестьяннарны атып үтерәләр. Антон Петров та кулга алына.

Бизнәдәге фетнә туктатылганнан соң да крестьяннар хәрәкәте шактый еллар дәвам итә әле. Әмма алар һәркайда хәрби көч белән бастырылып килә. Бары тик 1870 нче еллар башында гына дөньялар тынычланып китә. Сүз дә юк, мондый хәрәкәтләрнең, каршылыкның файдасы да булмый калмый. Шушы ыгы-зыгыдан файдаланып, Казан губернасында яшәгән, көчләп чукындырылган татарлар, православие диненнән баш тартып, мөселманлыкка күчә. Крестьяннарны тынычландыру йөзеннән, аграр реформаларны җайлаштыру эшләре дә карала. Шулай итеп, авылларда киеренкелек бетүгә таба бара.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хөрмәтле
Фидаил Бәдри улы ҖӘЛӘЛИЕВ!
Сезне тормышыгызның истәлекле һәм күркәм вакыйгаларның берсе – 85 яшьлек юбилеегыз белән ихлас котлыйбыз.

Кеше гомере – уянып килүче табигатьне сизелер-сизелмәс кенә сыйпап үтүче таң җиле кебек ул. Шул еллар эчендә әллә никадәр җилләр искән, сулар аккан. Гомер дигән асыл мизгелнең кадерен белеп, аннан тәм һәм ямь табып, ләззәтләнеп яшәвегез барыбызны да сөендерә.

Без сезне сизгер йөрәкле, нечкә күңелле, уртак эш өчен кешеләрне бергә туплап, алда торган бурычларны үтәүгә юнәлтүче сәләтле оештыручы, ару-талу белмәс тынгысыз замандашыбыз буларак беләбез.

Арча нефтебазасында эшләү дәверендә техник базаны үстерү, икътисадны ныгыту, хезмәткәрләрнең социаль-көнкүреш дәрәҗәсен күтәрү буенча куандырырлык эшләр башкардыгыз.

Сез утырткан мәһабәт зәңгәр чыршылар нык тамырлар җибәреп, инде кырык елдан артык оешмабызны бизәп, яңарыш, чисталык, яшәү символы булып үсеп утыралар.

Киләчәк тормышыгыз шул чыршылар кебек нык, матур булсын!

Сезне чын күңелдән туган көнегез белән тәбрик итәбез, алдагы көннәрегездә дә сайлаган кыйблагыздан тайпылмыйча, аяз көннәр кичерүегезне телибез.

Ходай сезне сәламәтлектән аермасын, барлык якты хыялларыгызны тормышка ашырсын, күңел көрлеге насыйп итсен.

Дусларыгызга, якыннарыгызга һәр көн сөенеп, тормыш ямен тоеп яшәгез!

«Арча нефть продуктлары» җәмгыяте коллективы

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы «Связьинвестнефтехим» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Сорокин** Валерий Юрьевич **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Массакүләм коммуникацияләрне һәм мәгълүмати технологияләрне үстерүгә зур өлеш кертүе, күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы «АйСиЭл» – КПО ВС» акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы рәисе **Дьячков** Виктор Васильевич **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «РОСИНКАС» берләшмәсе филиалы – «Казан» бүлекчәсе башлыгы **Вахитов** Вәсим Хуҗаян улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе хезмәткәрләре: идарәнең җитәкчесе урынбасары **Трофимова** Марина Викторовна, кулланучылар хокукларын яклау бүлеге баш белгече – эксперты **Шәмсетдинова** Диана Григорьевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «Сәйдәш» мәдәният үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе аккомпаниаторы **Бәдретдинов** Динар Айдар улына; «Татарстан Республикасының Немец йорты» автоном коммерциячел булмаган оешмасы музыканты, артисты **Илюшкина** Лидия Валериевнага; «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Филармония джаз-оркестры артисты **Калашников** Анатолий Анатольевичка; «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең бию ансамбле халык уен кораллары оркестры артисты **Миловидова** Венера Владимировнага; Кырым Республикасының «Кырым дәүләт филармониясе» дәүләт автоном мәдәният учреждениесе вокалчы артисты **Хафизова** Динара Мөнир кызына; «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе бию ансамбле балет артисты **Мәхмүдова** Рузана Рәис кызына; «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе бию ансамбле балет артисты **Сүлтиева** Эльмира Фирдинанд кызына; «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Синицына** Елена Валерьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының «Республика яшүсмерләр китапханәсе» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры **Вәлиуллина** Наилә Рафикъ кызына, «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең «Фондлар уку залы» секторы мөдире **Степанова** Фәния Гомәр кызына, Казан шәһәренең «11 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең теория фәннәре укытучысы **Фазлыева** Гүзәлия Илдус кызына, Казан шәһәренең «11 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең фортепиано классы укытучысы **Шәмсетдинова** Луиза Рим кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында» 2000 елның 31 маендагы 177 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 6 (5); 2007, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 47 пунктта «5» санынннан соң «, 6» санын өстәргә;

б) 48 пунктта «, 8» санын төшереп калдырырга;

2) кушымтада:

а) 47 пунктның икенче абзацында «5» санынннан соң «, 6» санын өстәргә;

б) 48 пунктның икенче абзацында «, 8» санын төшереп калдырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2011 елның 16 июнендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш); 2014, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

1 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров суд районы буенча җәмәгать судьясының 1 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Лушников һәм 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Лушников урамының күчәр сызыгы буйлап Коммунарлар, Дружина һәм Дежнев урамнары кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба Дежнев урамының күчәр сызыгы буйлап Аркылы Базар урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш юнәлешләрдә Аркылы Базар урамының күчәр сызыгы буйлап Лукницкий һәм Беренче Май урамнары белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк юнәлештә Лукницкий урамының күчәр сызыгы буйлап Октябрьнең 25 еллыгы урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм көнбатыш юнәлештә Октябрьнең 25 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап Деловая урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, уңга борыла һәм төньяк юнәлештә Деловая урамының күчәр сызыгы буйлап Краснококшайская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнбатышка таба Фрунзе һәм Чкалов урамнары белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба Фрунзе урамының күчәр сызыгы буйлап Коләхмәтов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, уңга борыла һәм төньяк юнәлештә Коләхмәтов урамының күчәр сызыгы буйлап Сабан һәм Батыршин урамнары кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә Батыршин урамының күчәр сызыгы буйлап Галимҗан Баруди урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, сулга борыла һәм төньяк юнәлештә Галимҗан Баруди урамының күчәр сызыгы буйлап Серов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм Серов урамының күчәр сызыгы буйлап Зур Крыловка, Ленская һәм Тверь урамнары кисешкән җиргә кадәр уза, сулга борыла һәм Ленская урамының күчәр сызыгы буйлап 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә Лушников һәм 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

2 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров суд районы буенча җәмәгать судьясының 2 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Фрунзе, Краснококшайская, Деловая һәм Галимҗан Баруди урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньякка таба, так яктагы йортларны кертеп, Деловая урамының күчәр сызыгы буйлап Октябрьнең 25 еллыгы урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Октябрьнең 25 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап Лукницкий урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм көньяк юнәлештә Лукницкий урамының күчәр сызыгы буйлап Беренче Май урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Беренче Май урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе территориясенең көнчыгыш чигенә кадәр бара, алга таба предприятие территориясен әйләнеп уза һәм төньяк-көнбатыш юнәлештә «787 км» тукталыш платформасына кадәр бара, аннары уңга борыла һәм Горький шоссесы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм көнчыгышка таба Горький шоссесының күчәр сызыгы буйлап Можайский урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә бакчаларның көньяк чикләре буйлап Восстание урамына кадәр бара, алга таба дары зиратының төньяк почмагы районында Восстание урамын кисеп үтә, зиратның төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап Сабан урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә Сабан һәм Батыршин урамнарының күчәр сызыклары буйлап, уң яктагы йортларны кертеп, Галимҗан Баруди урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк юнәлештә Галимҗан Баруди урамының күчәр сызыгы буйлап Фрунзе, Краснококшайская, Деловая һәм Галимҗан Баруди урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

3 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров суд районы буенча җәмәгать судьясының 3 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Лейтенант Красиков һәм Ильич урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньякка таба Ильич урамының күчәр сызыгы буйлап Революция урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм Революция урамының күчәр сызыгы буйлап тимер юллар белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә тимер юл буйлап Горький шоссесы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннан сулга борыла һәм төньяк-көнбатыш юнәлештә Горький шоссесы һәм Залесная урамының күчәр сызыклары буйлап М-7 федераль трассасының автомобиль юллары чишелешенә һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Зеленодольск муниципаль районы чигенә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк юнәлештә автомобиль трассасы буйлап Подгорная урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм көнчыгышка таба Подгорная урамының күчәр сызыгы буйлап Бирюзовая урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, Бирюзовая һәм Лейтенант Красиков урамнарының күчәр сызыклары буйлап Лейтенант Красиков һәм Ильич урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

4 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров суд районы буенча җәмәгать судьясының 4 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Лейтенант Красиков һәм Ильич урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньякка таба Ильич урамының күчәр сызыгы буйлап Революция урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм көнчыгышка таба Революция урамының күчәр сызыгы буйлап тимер юллар белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә «32 нче хәрби шәһәрчек» микрорайоны территориясе чиге буйлап бара, алга таба тимер юллар буйлап бакчачылык ширкәтләре территориясе чигенә кадәр уза, әлеге территорияне әйләнеп уза һәм «Пролетарий» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте районында тимер юллар киселешенә килеп чыга, аннары көнчыгыш юнәлештә тимер юллар буйлап Кызыл Армия урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм көньяк юнәлештә Кызыл Армия урамының күчәр сызыгы буйлап Клара Цеткин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары Клара Цеткин урамының күчәр сызыгы буйлап Боевая урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба катгый көньяк юнәлештә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча узучы чигенә кадәр уза һәм Идел елгасы аша салынган күпернең сул як яр терәге янында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Югары Ослан һәм Зеленодольск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында урнашкан тоташу ноктасына кадәр бара, алга таба төньякка һәм төньяк-көнбатышка таба, сул яктагы территорияне дә кертеп, тимер юллар белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба Подгорная урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көнчыгышка таба Подгорная һәм Бирюзовая урамнарының күчәр сызыклары буйлап Лейтенант Красиков һәм Ильич урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

5 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров суд районы буенча җәмәгать судьясының 5 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Лушников һәм 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Лушников урамының күчәр сызыгы буйлап Коммунарлар, Дружина һәм Дежнев урамнары белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньякка таба Дежнев урамының күчәр сызыгы буйлап Аркылы Базар урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көнбатышка таба Аркылы Базар урамының күчәр сызыгы буйлап Беренче Май урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Беренче Май урамының күчәр сызыгы буйлап «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе территориясенең көнчыгыш чигенә кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба предприятие территориясе чиге буйлап предприятие территориясе коймасының көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба туп-туры көньякка таба тимер юлларга кадәр уза, сулга борыла һәм, сул якта урнашкан Свято-Успенье Зилант хатын-кызлар монастыре территориясен кертеп, көнчыгыш юнәлештә тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буенча Кызыл Армия урамына кадәр уза, аннары көньякка борыла һәм Кызыл Армия урамының күчәр сызыгы буйлап Кызыл Армия һәм Клара Цеткин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба Клара Цеткин урамының күчәр сызыгы буйлап Клара Цеткин, Большая һәм Боевая урамнары тоташкан урында урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба туп-туры көньякка таба Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Куйбышев сусаклагычы акваториясе аша узучы чигенә кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буенча Куйбышев сусаклагычы (Идел елгасы) акваториясе буенча Казан шәһәре Вахитов районының административ чиге белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Казан шәһәре Киров районының Вахитов районы белән административ чиге буенча Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча бара, аның уң яры өлешендә Адмиралтейская дамбасын кисеп үтә һәм Казансу елгасы акваториясендә Казан Кремленең Воскресенская башнясыннан төньяк-көнчыгышка таба 150 метрда Казан шәһәренең Киров, Вахитов һәм Яңа Савин районнарының чикләре тоташкан урында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк юнәлештә «Казан» гаилә үзәге янындагы мәйданның төньяк-көнбатыш почмагында Казан шәһәренең Киров, Мәскәү һәм Яңа Савин районнарының чикләре тоташкан урында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Декабристлар урамының сул ягы буйлап, «Кәҗә бистәсе» метро станциясе бинасын кертмичә, Мулланур Вахитов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнбатыш юнәлештә Мулланур Вахитов урамының күчәр сызыгы буйлап 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм төньяк юнәлештә 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамының күчәр сызыгы буйлап Лушников һәм 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

6 нчы суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Киров суд районы буенча җәмәгать судьясының 6 нчы суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Можайский урамының һәм Горький шоссесының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Горький шоссесының күчәр сызыгы буйлап һәм алга таба Залесная урамының күчәр сызыгы буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Зеленодольск муниципаль районы белән чигенә кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм төньяк һәм төньяк-көнчыгыш юнәлешләрдә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре Мәскәү районы белән чиге буйлап Ремплер авылының көньяк-көнчыгыш кырыенда урнашкан ноктага кадәр бара, аннары көнчыгыш юнәлештә «Лебяжье» шәһәр урман паркының төньяк чиге буйлап бара, алга таба Химия урамының күчәр сызыгы буйлап Можайский урамының һәм Горький шоссесының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.»;

2) 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

1 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча җәмәгать судьясының 1 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Ленская һәм 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамының күчәр сызыгы буйлап Мулланур Вахитов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә Мулланур Вахитов урамының күчәр сызыгы буйлап Декабристлар урамы белән киселешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм Декабристлар урамының җөп санлы ягы буйлап, «Кәҗә бистәсе» метро станциясе бинасын кертеп, Декабристлар урамын кисеп уза һәм «Казан» гаилә үзәге янындагы мәйданның төньяк-көнбатышында Казан шәһәре Мәскәү, Киров һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм Бондаренко урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба сулга борыла һәм төньяк юнәлештә Бондаренко урамының күчәр сызыгы буйлап Ямашев проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм Ямашев проспектының һәм Ленская урамының күчәр сызыклары буйлап көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш юнәлешләрдә Ленская һәм 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

2 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча җәмәгать судьясының 2 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Академик Королев урамының һәм Ибраһимов проспектының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көнбатышка таба Академик Королев урамының күчәр сызыгы буйлап Декабристлар урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Декабристлар урамының күчәр сызыгы буйлап Ямашев проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көнчыгышка таба Ямашев проспектының күчәр сызыгы буйлап Ибраһимов проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба Ибраһимов проспектының күчәр сызыгы буйлап Академик Королев урамының һәм Ибраһимов проспектының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

3 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча җәмәгать судьясының 3 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Восстание һәм Декабристлар урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көнбатышка таба Восстание урамының күчәр сызыгы буйлап Коләхмәтов һәм Васильченко урамнары белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм көньяк юнәлештә Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап Восход урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм көньяк-көнбатыш юнәлештә Восход урамының күчәр сызыгы буйлап Серов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Серов урамының күчәр сызыгы буйлап Ленская урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары Ленская урамының күчәр сызыгы буйлап Декабристлар урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк юнәлештә Декабристлар урамының күчәр сызыгы буйлап Восстание һәм Декабристлар урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

4 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча җәмәгать судьясының 4 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Коләхмәтов һәм Восстание урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньякка таба Коләхмәтов урамының күчәр сызыгы буйлап Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап Восход урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм Восход һәм Галимҗан Баруди урамнарының күчәр сызыклары буйлап Батыршин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатыш юнәлештә Батыршин урамының күчәр сызыгы буйлап Коләхмәтов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм төньяк юнәлештә Коләхмәтов урамының күчәр сызыгы буйлап Коләхмәтов һәм Восстание урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

5 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча җәмәгать судьясының 5 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Коләхмәтов һәм Восстание урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көнчыгышка таба Восход урамының күчәр сызыгы буйлап Декабристлар урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм төньяк юнәлештә Декабристлар урамының күчәр сызыгы буйлап Академик Королев урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Академик Королев урамының күчәр сызыгы буйлап Ибраһимов проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньякка таба Ибраһимов проспектының күчәр сызыгы буйлап тимер юллар белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм көнчыгышка таба тимер юллар буйлап Хлебозаводская урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк юнәлештә Васильченко урамының күчәр сызыгы буйлап Коләхмәтов, Восстание һәм Васильченко урамнары чатында урнашкан скверның көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм көнбатыш юнәлештә Восстание урамының күчәр сызыгы буйлап Восстание урамындагы 93 нче йортка кадәр уза, сулга борыла һәм Окольная урамының күчәр сызыгы буйлап Окольная урамындагы 94/2 нче йорт районында Бакалея урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә Бакалея урамының күчәр сызыгы буйлап Коләхмәтов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба сулга борыла һәм төньяк юнәлештә Коләхмәтов урамының күчәр сызыгы буйлап Восстание һәм Коләхмәтов урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

6 нчы суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча җәмәгать судьясының 6 нчы суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Васильченко, Восстание һәм Коләхмәтов урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көнбатышка таба Восстание урамының күчәр сызыгы буйлап Восстание урамындагы 93 нче йортка кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм Окольная урамының күчәр сызыгы буйлап Окольная урамындагы 94/2 нче йорт районында Бакалея урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Коләхмәтов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, уңга борыла һәм көньяк-көнбатыш юнәлештә Батыршин һәм Сабан урамнары белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатыш юнәлештә Сабан урамының күчәр сызыгы буйлап «Дары» зираты чигенә кадәр уза, алга таба «Дары» зиратының көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап Восстание урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, «Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең сәнәгать зонасы коймасы янында урнашкан бакчаларның көньяк чикләре районында аны кисеп үтә, аннары көньяк-көнбатышка таба, бакчачылык ширкәте һәм сәнәгать зонасы территорияләрен кертеп, «Тасма-Холдинг» бакчачылык ширкәтенең көньяк чиге буйлап Горький шоссесындагы 26 нчы йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба йонны беренчел эшкәртү фабрикасы складлары территориясенең көнчыгыш чиге буйлап бара, юл үткәргечне кисеп үтә, алга таба «Казан Органик синтез» ачык акционер җәмгыятенең сәнәгать мәйданчыгына бара торган юл буенча «Лебяжье» шәһәр урман паркы аланына кадәр уза, «Лебяжье» шәһәр урман паркының көнчыгыш чиге буйлап Химия урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары шул ук юнәлештә Тэцевская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм, уң якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, көнчыгышка таба Тэцевская урамының күчәр сызыгы буйлап Теплично-Комбинатская урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк юнәлештә, уң якта урнашкан офис биналарын кертеп, Тэцевская урамындагы ярдәмче юл буйлап Теплично-Комбинатская урамының дәвамы булган тимер юлга бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, уңга борыла һәм көнбатышка таба тимер юллар буйлап Васильченко урамындагы 6 нчы йорт янында урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә, уң якта урнашкан сәнәгать зонасы һәм Васильченко исемендәге сквер территорияләрен кертеп, Васильченко урамының күчәр сызыгы буйлап Восстание, Коләхмәтов һәм Васильченко урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

7 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Мәскәү суд районы буенча җәмәгать судьясының 7 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Гудованцев һәм Тэцевская урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып төньякка таба Гудованцев урамының күчәр сызыгы буйлап шәһәр кырыена кадәр уза, алга таба Гудованцев урамын дәвам итеп, шул ук юнәлештә Казан шәһәре Мәскәү районының Авиатөзелеш районы белән административ чиге буенча бакчачылык ширкәтләренең, урман утыртмасының көнбатыш чикләре буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап Ремплер авылының көньяк-көнчыгыш кырыенда Казан шәһәре Киров районының административ чиге белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә, «Казан Органик синтез» ачык акционер җәмгыятенең сәнәгать зонасы һәм «3 нче Күперләр төзү отряды» торак шәһәрчеге территорияләрен кертеп, «Лебяжье» шәһәр урман паркының төньяк чиге буйлап, Казан шәһәре Мәскәү районының Киров районы белән административ чиге буенча Химия урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба сулга борыла һәм Химия урамының күчәр сызыгы буйлап Тэцевская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнчыгышка таба, уң якта урнашкан сәнәгать зонасы һәм «Жилплощадка» микрорайоны территорияләрен кертеп, Тэцевская урамының күчәр сызыгы буйлап Гудованцев һәм Тэцевская урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.».

3 статья

Әлеге Закон 2022 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 12-ТРЗ

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5; 2013, № 10; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль районда бер муниципаль район муниципаль комиссиясе, шәһәр округында бер шәһәр округы муниципаль комиссиясе төзелә.

Шәһәр округы вәкиллекле органы карары буенча, шәһәр округы муниципаль комиссиясеннән тыш, өстәмә рәвештә шәһәр округы территориясе өлешендә эшләүче муниципаль комиссияләр (алга таба – шәһәр эче муниципаль комиссияләре) төзелергә мөмкин, ләкин шәһәр эче муниципаль комиссиясе Казан шәһәре шәһәр округында дүрттән артык һәм Чаллы шәһәре шәһәр округында өчтән артык төзелә алмый.

Компетенцияләрне шәһәр округы муниципаль комиссиясе һәм шәһәр эче муниципаль комиссияләре арасында бүлү тиешле шәһәр округы вәкиллекле органының хокукый акты белән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2) 6 статьяда:

а) 1 өлештә «, 25 кешедән артык» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «урынбасары» сүзеннән соң «(урынбасарлары)» сүзен өстәргә;

3) 7 статьяда:

а) 1 өлештә «, 15 кешедән артык» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «урынбасары» сүзеннән соң «(урынбасарлары)» сүзен өстәргә;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Рәис җирле администрация башлыгы урынбасарлары арасыннан (шәһәр эче муниципаль комиссиясендә – шәһәр округы җирле администрациясе территориаль органы җитәкчесе урынбасарлары арасыннан) билгеләп куела.

Рәис муниципаль комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, муниципаль комиссиягә йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен шәхси җаваплы була, хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, муниципаль комиссия утырышын алып бара; муниципаль комиссия кабул итә торган документларга имза сала. Рәис булмаган очракта, аның функцияләрен рәис урынбасары (рәис урынбасарларының рәис тарафыннан билгеләнгән берсе) башкара.»;

4) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 19^{1} пункт өстәргә:

«19^{1}) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы территориясендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эше турында хисапларны, шулай ук Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның сукбайлыгын, күзәтүчесезлеген, наркоманиясен, токсикоманиясен, алкоголизмын, хокук бозуларын, һәлак булуларын һәм имгәнүләрен кисәтү чаралары, хезмәт, торак һәм башка хокуклары бозылу турында башка мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әзерли һәм җибәрә, әлеге өлкәдә вәзгыятьне яхшырту буенча тәкъдимнәр кертә;»;

5) 17 статьяда:

а) 7 өлештә «дәүләт хакимиятенең тиешле органнарына, җирле үзидарә органнарына, барлык оештыру-хо-

кукый рәвешләрдәге һәм милек рәвешләрендәге оешмаларга» сүзләрен «тиешле дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге һәм милек рәвешләрендәге оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга, «оешмаларга» сүзеннән соң «, гражданнарга» сүзен өстәргә;

б) 9 өлештә «күрсәтмәләрен» сүзеннән соң «тиешле» сүзен өстәргә, «шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга.

2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 13-ТРЗ

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланың икенче абзацында «(алга таба – гадәттән тыш хәлләр)» сүзләрен «(алга таба шулай ук – гадәттән тыш хәлләр)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда:

а) икенче өлештә «оешмалар администрациясе» сүзләрен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче өлеш өстәргә:

«Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мәгълүматны гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы идарә органнарына билгеләнгән тәртиптә үз вакытында тапшырырга тиеш.»;

в) өченче өлешне дүртенче өлеш дип санарга;

3) 9 статьяның беренче өлешендәге дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы булганда яисә алар барлыкка килгәндә эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү;»;

4) 10 статьяда:

а) тугызынчы абзацта «, гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын уздыру турында карарлар кабул итү һәм шушы чараларны уздыруны оештыру» сүзләрен «турында карарлар кабул итү, гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы булганда яисә алар барлыкка килгәндә эвакуация чараларын үткәрүне оештыру һәм гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«федераль, регионара, региональ, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрне юкка чыгарганда гадәттән тыш хәл зонасындагы торак урыннарында Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның яшәү, гадәттән тыш хәл аркасында тормыш-көнкүреше шартлары бозылу һәм мөлкәте юкка чыгу фактларын билгеләү.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 14-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешендәге 37 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37) федераль закон нигезендә җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү;»;

2) 16 статьяның 1 өлешендәге 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32) федераль закон нигезендә муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү;»;

3) 17 статьяның 1 өлешендәге 41 пунктны түбәндәге редакциядә бән итәргә:

«41) федераль закон нигезендә шәһәр округы ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү;»;

4) 33 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5^1 өлеш өстәргә:

«5^1. Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне үткәрү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы финанс органының күрсәтелгән тикшерүне үткәрүдә катнашу тәртибе әлеге Законга 3 нче кушымтада билгеләнә.»;

5) түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы финанс органының Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне үткәрүдә катнашу тәртибе

1. Татарстан Республикасы финанс органы Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның (алга таба – кандидатлар) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне үткәрүдә Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы башлыгы (алга таба – муниципаль берәмлек башлыгы) мөрәҗәгате нигезендә катнаша.

2. Татарстан Республикасы финанс органының кандидатларны тикшерүдә катнашуы муниципаль берәмлек башлыгы белән тәкъдим ителгән кандидатларның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

3. Кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне Татарстан Республикасы финанс органында төзелә торган квалификация комиссиясе гамәлгә ашыра. Квалификация комиссиясе турында нигезләмә Татарстан Республикасы финанс органы тарафыннан раслана. Тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән рәвештә Татарстан Республикасы финанс органы бәяләмәсе кабул ителә.

4. Муниципаль берәмлек башлыгы мөрәҗәгатенә кандидатларның түбәндәге документлары кушып бирелә:

1) кандидатның белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең «Икътисад һәм идарә» берләштерелгән төркеменә керә торган белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә белгечлек, магистратура дәрәҗәсендәге югары белеме булуын раслый торган, дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы узу нәтиҗәләре буенча белем турында һәм квалификация хакында бирелгән документларның йә икътисад фәннәре кандидаты дипломының нотариус яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

2) хезмәт кенәгәсенең (булганда) нотариус яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яисә хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;

3) кандидатның шәхси белешмәләрне эшкәртүгә язмача ризалыгы;

4) кандидатны Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасына билгеләп куюны нигезләү.

5. Кандидатның тиешле вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле һөнәри белемнәрен тикшерү максатларында квалификация комиссиясе тарафыннан кандидатка тест һәм индивидуаль әңгәмә үткәрелә.

6. Кандидатларга тест үткәрү өчен кирәкле сорауларның якынча исемлеге Татарстан Республикасы финанс органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

7. Квалификация комиссиясе тарафыннан тикшерү үткәрү һәм Татарстан Республикасы финанс органының бәяләмәсен әзерләү срогы муниципаль берәмлек башлыгының мөрәҗәгате Татарстан Республикасы финанс органына кергән көннән алып 30 эш көненнән дә артыграк була алмый.

8. Квалификация комиссиясе тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кандидатның квалификация таләпләренә туры килүе турында;

2) кандидатның квалификация таләпләренә туры килмәве турында.

9. Татарстан Республикасы финанс органы бәяләмәсе, расланган көненнән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгатьне җибәргән муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

Татарстан Республикасы финанс органының
Татарстан Республикасы муниципаль районы,
шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация
таләпләренә туры килүен тикшерүне үткәрүдә
катнашу тәртибенә кушымта

«Раслыйм»

____
(Татарстан Республикасы
финанс органы җитәкчесе)

20___ елның «__» _________

____
(Татарстан Республикасы финанс органы исеме)

Татарстан Республикасы муниципаль районы,
шәһәр округы финанс органы җитәкчесе
вазыйфасын биләүгә кандидатның квалификация
таләпләренә туры килүен тикшерү
нәтиҗәләре турында
бәяләмә № ___

Казан шәһәре 20__ елның «____»_________

____
(Татарстан Республикасы финанс органы исеме)

____
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге,
шәһәр округы исеме)

финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидат

____
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү үткәрү турында

____
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге,
шәһәр округы исеме)

муниципаль берәмлеге башлыгы мөрәҗәгате каралды. Тәкъдим ителгән документлар нигезендә һәм үткәрелгән тест нәтиҗәләрен һәм индивидуаль әңгәмәне исәпкә алып,

____
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге,
шәһәр округы исеме)

финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидат

____
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

квалификация таләпләренә туры килүе турындагы мәсьәлә каралды.

Тикшерү барышында квалификация таләпләренә туры килү/туры килмәү билгеләнде (тиешлесенең астына сызарга).

____
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге,
шәһәр округы исеме)

финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидат

____
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

квалификация таләпләренә туры килә/туры килми
(тиешлесенең астына сызарга).

Тикшерү барышында түбәндәге квалификация таләпләренә туры килмәү билгеләнде<*>:

1)_____________________________________
2)_____________________________________
3)_____________________________________
4)_____________________________________

<*> Кандидатның квалификация таләпләренә туры килмәве билгеләнгәндә тутырыла.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 15-ТРЗ

«Һөнәр берлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

«Һөнәр берлекләре турында» 1995 елның 18 гыйнварындагы 2303-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (2019 елның 27 июнендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1995, № 1; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш), «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре хезмәткәрләрен,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе җинаять-үтәтү системасы хезмәткәрләрен, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары хезмәткәрләрен,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 16-ТРЗ

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1–2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 11 пунктында «, мәктәп спорты» сүзләрен «(мәктәп спортын да кертеп)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5 статьяның 6 пунктында «спорт судьялары,» сүзләреннән соң «тренер-укытучылар (алга таба шулай ук – тренерлар)» сүзләрен өстәргә;

3) 6 статьяда:

а) 1 өлештә:

1^1 пунктта «, мәктәп спортын» сүзләрен «(мәктәп спортын да кертеп)» сүзләренә алмаштырырга;

4^1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4^1) балалар-яшүсмерләр спортын үстерү;»;

9^1 һәм 9^3 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) 2 өлешнең 2 пунктында «тренировка» сүзен «укыту-тренировка» сүзенә алмаштырырга;

4) 9 статьяның 2 өлешендә «тренировка» сүзен «укыту-тренировка» сүзенә алмаштырырга;

5) 11 статьяда:

а) 1 өлештә «тренировка» сүзен «укыту-тренировка» сүзенә алмаштырырга;

б) 4^1 өлешнең 1 пунктында «тренировка» сүзен «укыту-тренировка» сүзенә алмаштырырга;

6) 14 статьяның 4 өлешендә «спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар» сүзләрен «спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

7) 18 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Спорт әзерлеге узучы затның спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмага каравы мондый оешманың әлеге затны Россия Федерациясе бюджет системасы тиешле бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән дәүләт заданиесе (муниципаль задание) яисә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә нигезендә спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программасы буенча укырга кабул итү турындагы боеру акты нигезендә билгеләнә.»;

б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

8) 19 статьяның 2 өлешендә:

а) 2 пунктта «физкультура-спорт ягыннан әзерләүнең» сүзләрен «физик яктан үстерү һәм физик әзерләү буенча» сүзләренә алмаштырырга, «чараларын» сүзен «чаралар» сүзенә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «физик культура күнекмәләре» сүзләрен «хәрәкәтләнү күнекмәләре, физик культура турында белемнәр» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «дәресләр вакытында» сүзләреннән соң «һәм дәресләрдән тыш вакытта» сүзләрен өстәргә;

9) 22 статьяның 7 өлешендә «балалар-яшүсмерләрнең спорт-адаптив мәктәпләрен» сүзләрен «спорт мәктәпләрен, шул исәптән адаптив спорт буенча спорт мәктәпләрен» сүзләренә алмаштырырга;

10) 23 статьяның 2 өлешендә «эшләүне оештыру» сүзләрен «эшләү» сүзенә алмаштырырга;

11) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24 статья. **Спорт әзерлеген оештыру**

Спорт әзерлеген оештыру Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

12) 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 статья. **Федераль спорт әзерлеге стандартларының үтәлешенә җәмәгать контроле**

Бөтенроссия спорт федерацияләре һәм аккредитацияләнгән республика спорт федерацияләре, аларның вәкилләре спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан тиешле спорт төрләре буенча федераль спорт әзерлеге стандартларының үтәлешенә җәмәгать контролен физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

13) 26 статьяда:

а) исемдә «, республика спорт әзерлеге үзәкләре» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Республика спорт әзерлеге үзәкләре физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең махсус вәкаләтле органы тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә оештырыла.»;

14) 29 статьяның 2 өлешендә «спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган» сүзләрен «спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 17-ТРЗ

Хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12);

2) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8);

3) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 11 октябрендәге 101-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш);

4) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 3 февралендәге 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2);

5) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 29 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш);

6) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2009 елның 4 декабрендәге 61-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 12 (I өлеш);

7) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 15 мартындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 3);

8) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 17 маендагы 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш);

9) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 6 (II өлеш);

10) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7);

11) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7);

12) «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2021 елның 5 мартындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 20 (I өлеш).

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 18-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ

18 март, 2022 ел Казан ш. № 169/1432

2022 елның февралендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2022 елның февралендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 11 март, 2022 ел, № 98 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карар бирә:

1. 2022 елның февралендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 11 март, 2022 ел, № 98 карарында урын алган) расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының 2022 елның февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

3. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2022 елның февралендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

4. Бу карарны «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

5. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В.Сквордяковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе — А.С.Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре — Н.П. Борисова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ КАРАРЫ

гражданин А.В. Орлов шикаятенә бәйле рәвештә «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарындагы 4 пунктының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча

Казан шәһәре 2022 елның 1 марты

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып, ачык суд утырышында «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарындагы 4 пунктының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин А.В. Орлов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья М.М. Хәйруллин мәгълүматын, яклар – гражданин А.В. Орлов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы юридик бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе Ф.М. Мөхәммәдиева аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.В. Орлов «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 732 номерлы карары) 4 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 732 номерлы карарының 4 пункты нигезендә, ата-анасы белән яшәүче һәм үз гаиләләрен төземәгән ун һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр (алга таба шулай ук – ун һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр) өчен тиешле елга Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлегенә кертелгән күпбалалы гаиләләрнең гомуми санының 1 проценты һәм кимендә бер гаилә күләмендә беренче чиратта торак белән тәэмин итү буенча еллык квота билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин А.В. Орлов хатыны һәм балалары белән 2013 елдан бирле торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә тора һәм, күпбалалы гаилә буларак, алар гражданның Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын алу өчен субсидия алу хокукын раслый торган сертификат алу хокукына ия. Ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән беренче чиратта тәэмин итү буенча еллык квотаны билгеләүче дәгъва белдерелә торган норма нигезендә мөрәҗәгать итүче гаиләсе Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба шулай ук – Министрлык) тарафыннан формалаштырылган 2018 елга сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертелгән. Субсидия күләмен билгеләгәндә, Министрлык тарафыннан 2013 елда мөрәҗәгать итүче тарафыннан фатирны читләштерү буенча алыш-биреш исәпкә алынган. Кулланылган исәп-хисап белән килешмичә, гражданин А.В. Орлов гаиләсе тәкъдим ителгән күләмдә субсидияне алмаган. Әлеге алыш-бирешне исәпкә алып, аның нигезендә сертификат күләмен исәпләү башкарылган норматив хокукый нигезләмә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан конституциячел түгел дип танылган иде (2019 елның 25 декабрендәге 87-П номерлы карар).

2019 елда мөрәҗәгать итүче гаиләсендә бала үлүгә карамастан, ул үзенең гаиләсен чираттагы елга сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертү турында, мондый исемлеккә алар инде ун бала белән 2018 елда кертелүен исәпкә алып, вәкаләтле органга гариза белән мөрәҗәгать иткән. Әмма аның гаиләсе, беренче чиратта торак белән тәэмин итү шартларына туры килми башлау сәбәпле, китерелгән исемлеккә кертелмәгән. Шуңа бәйле рәвештә алар сертификат алуны гомуми тәртиптә, уннан кимрәк балалары булган гаиләләр белән беррәттән, ягъни җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә кую вакытыннан чыгып формалаштырыла торган чират тәртибендә көтәргә мәҗбүр булганнар.

Гражданин А.В. Орлов, дәгъва белдерелә торган нигезләмә, ун баласы булган гаиләдә бала үлгәннән соң, беренче чиратта торак белән тәэмин ителү хокукын югалтуны күз алдында тотмый, дип саный. Аның фикеренчә, мондый гаилә беренче чиратта торак алу хокукына инде алдан ия булганга күрә, ул, бер баласы үлүенә карамастан, тәэмин ителергә тиеш. Әмма, аның раславынча, хокук куллану практикасы түбәндәгечә килеп чыга: планлаштырылган елга сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертелгән, әмма көтелмәгән хәлләр аркасында аларның саны үзгәргән күпбалалы гаиләләр сертификат ала алмыйлар, бу исә конституциячел дип санала алмый һәм гаделлек принцибын бозуга китерә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.В. Орлов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче өлеш), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы – сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм картлык дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта; һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә бүтән органнар компетенциясенә кергән барлык очракларда фактагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пункты ата-аналары белән бергә яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган ун һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән беренче чиратта тәэмин итү өчен хокукый нигез булып торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 пунктының 24 пунктчасы нигезендә балалары булган гаиләләргә (шул исәптән күпбалалы гаиләләргә, ялгыз ата-анага) социаль ярдәм мәсьәләләрен хәл итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының уртак карамактагы мәсьәләләр буенча әлеге органнар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән мөстәкыйль гамәлгә ашырыла торган (федераль бюджеттан кергән субвенцияләрдән тыш) вәкаләтләренә керә. Шулай ук әлеге Федераль законда түбәндәгеләр каралган: Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын федераль законнарда күрсәтелгән хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйсез рәвештә билгеләргә хокуклы. Аталган вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла һәм федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

«Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән Россия Федерациясе составындагы республикалар хөкүмәтләренә, крайларның, өлкәләрнең, автоном берәмлекләрнең, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләренең башкарма хакимият органнарына, регионның социаль-икътисадый һәм демографик үсешендә милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, күпбалалы һәм өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ гаиләләр категорияләрен ачыклау һәм күпбалалы гаиләләр өчен социаль ярдәм чараларын билгеләү йөкләнгән (1 пунктның «а», «б» пунктчалары).

Күрсәтелгән норматив хокукый актларның дәвамы буларак «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карала торган карарны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль законнар нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында, дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта (38 статья, беренче һәм өченче өлешләр) дип беркетә; һәркемгә балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш). Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7, 38 (1 өлеш) һәм 39 (1 өлеш) статьяларында билгеләнгән.

Китерелгән конституциячел нигезләмәләргә Бала хокуклары турында конвенция күрсәтмәләре туры килә (БМО Генераль Ассамблеясының 1989 елның 20 ноябрендәге карары белән хупланган), ул тормышның барлык өлкәләрендә дә балалар мәнфәгатьләре һәм яшәеше өстенлеге принцибына таянып, аны имзалаган дәүләтләргә – һәр баланың физик, акыл, рухи, әхлакый һәм социаль үсеше өчен кирәк булган тормыш дәрәҗәсенә хокукын танудан чыгып, – ата-аналар һәм бала тәрбияләүче һәм аның өчен җаваплы булган башка затларның үзләренең сәләте һәм финанс мөмкинлекләре чикләрендә моның өчен шартлар тудырырга тиешлеген исәпкә алып, балаларга иминлек өчен кирәкле булган яклауны һәм кайгыртуны тәэмин итәр өчен барлык закон һәм административ чаралар күрүне йөкли (3 статьяның 2 пункты, 27 статьяның 1 һәм 2 пунктлары).

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми; әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 38 һәм 39 статьялары белән беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә гаилә һәм балаларны социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар, 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә). Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, үзенә бирелгән дискрецион вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карары белән Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан үзләренә беркетелгән торак урыннары булмаган затларны торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләрен раслаган, аларда ата-анасы белән бергә теркәлгән һәм бергә яшәүче һәм үз гаиләләрен төземәгән биш һәм аннан да күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең торак белән тәэмин итү өчен сертификат алу хокукын билгеләгән. Соңыннан әлеге кагыйдәләр үз көчен югалткан дип танылган һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең яңа редакциясе расланган (алга таба шулай ук – Кагыйдәләр), анда ата-анасы белән яшәүче һәм үз гаиләләрен төземәгән биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр (үз гаиләләрен төзегән күпбалалы гаилә балаларына никахта торучы яисә үз баласы (балалары) булган балигъ булган балалар керә) өчен билгеләнгән аталган социаль ярдәм чарасы 4 пунктның «а» пунктчасында беркетелгән. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм ата-анасы белән яшәүче һәм үз гаиләләрен төземәгән ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында, мондый гаиләләр өчен беренче чират тәртибендә торак белән тәэмин итү буенча тиешле елга Татарстан Республикасындагы күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлегенә кертелгән күпбалалы гаиләләрнең гомуми саныннан 1 процент һәм иң кимендә бер гаилә күләмендә еллык квота билгеләүне күздә тоткан карала торган 4 пункт белән аны тулыландырып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2011 елның 20 декабрендәге 1021 номерлы карары белән шикаять белдерелә торган карарга үзгәреш керткән.

Татарстан Республикасы Конституция судының хокукый позициясе нигезендә, үзенең хокукый табигате буенча әлеге социаль ярдәм чарасы социаль тәэмин итүнең мәҗбүри төренә керми һәм, асылда, әлеге гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен яхшыртуның өстәмә алымы буларак билгеләнә (2011 елның 5 октябрендәге 44-П номерлы, 2013 елның 10 июлендәге 54-П номерлы, 2019 елның 25 декабрендәге 87-П номерлы карарлар).

3.1. Дәгъва белдерелә торган норманың хокукый мәгънәсеннән һәм сүзгә-сүз эчтәлегеннән чыгып, анда ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр өчен беренче чиратта торак белән тәэмин итү буенча еллык квота рәвешендә билгеләнгән гарантия уңай демографик тенденцияләрне стимуллаштыруга һәм беркетүгә, мондый гаиләләргә аерым гавами-хокукый статус бирүгә һәм аларга шулай ук торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган, ләкин балалары азрак булган күпбалалы гаиләләр арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын алганда өстенлекләр бирүгә юнәлдерелгән.

Ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрнең Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән торак урын алу хокукын гамәлгә ашыру механизмы Кагыйдәләр белән регламентланган, алар нигезендә әлеге гаиләләргә бу хокукны раслаучы исемле таныклык булган сертификат бирелә (2 пункт). Шуңа бәйле рәвештә дәгъва белдерелә торган норманың конституциячеллеген гражданин А.В. Орлов тарафыннан белдерелгән аспектта бәяләү сертификат бирү тәртибен билгели торган Кагыйдәләр нигезләмәләре белән аның норматив бәйләнешеннән башка мөмкин түгел. Мондый алым дәгъва белдерелә торган нормада каралган хокук үзеннән-үзе, аның фактта гамәлгә ашырылуын тикшермичә, юридик әһәмияткә ия булмавы белән бәйле, чөнки моннан башка анда салынган гарантияләрнең чын мәгънәсен бәяләү мөмкин түгел. Карала торган хокук гражданнар ягыннан да, шулай ук вәкаләтле гавами хакимият органнары ягыннан да үзара бәйләнешле этаплар кысаларында тормышка ашырыла торган гамәлләр комплексын башкару зарурлыгын беркетүче Кагыйдәләрнең нигезләмәләрендә норматив гамәлгә ашырыла: беренче чиратта торак белән тәэмин итү квотасын исәпкә алып, сертификат алуга дәгъва итүче күпбалалы гаиләләр исемлеген формалаштыру һәм аннан соң сертификат бирү.

Башлангыч этапта сертификат алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертү өчен гражданнар Кагыйдәләрнең 9 пунктында каралган хокукын раслый торган документларын үзләре торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә торган җирле үзидарә органнарына тапшыралар. Җирле үзидарә органнары, әлеге документларны тапшырган көннән алып, аларны тикшерү эшен оештыралар, аның нәтиҗәләре буенча гражданның сертификат алу хокукын тану һәм аны тиешле исемлекләргә кертү йә гражданның мондый хокукын танудан баш тарту турында карар кабул ителә (12 пункт). Кагыйдәләрнең 15 пункты нигезендә җирле үзидарә органнары ел саен, 1 октябрьгә кадәр, планлаштырыла торган елга гражданнар исемлекләрен формалаштыра һәм аларны Министрлыкка кертә, ул, Кагыйдәләрнең 16 пункты нигезендә, 1 ноябрьгә кадәр Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлеген (алга таба – Җыелма исемлек) планлаштырыла торган елга гражданнар җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куелган шул ук хронологик эзлеклелектә формалаштыра һәм раслый; Җыелма исемлекне раслаганнан соң, җирле үзидарә органнары Министрлыкның соравы буенча Җыелма исемлеккә кертелгән гражданнарның билгеләнгән тәртиптә расланган хокукын раслый торган документларын үз эченә алган исәпкә алу эшләре күчермәләрен кертә (16.1 пункт).

Әлеге исемлекләр нигезендә, Кагыйдәләрнең 17 пункты буенча, Министрлык, тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә каралган акчалар чикләрендә ел саен, 1 декабрьгә кадәр, планлаштырыла торган елда, ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне беренче чиратта торак белән тәэмин итү квотасын исәпкә алып, сертификатлар алучы гражданнар исемлеген төзи (алга таба – сертификатлар алучы гражданнар исемлеге).

Китерелгән хокукый җайга салу, мөрәҗәгать итүчеләр ягыннан да, җирле үзидарә органнары һәм Министрлык ягыннан да законсыз гамәлләрне булдырмас өчен, Кагыйдәләрдә билгеләнгән срокларда мәгълүмат тапшыруның нәтиҗәле процедурасын тормышка ашыруга, дәүләт социаль ярдәмен күрсәтүнең адреслылыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар чикләрендә торак бүлеп бирү планлаштырыла торган күпбалалы гаиләләр санын ачыклау зарурлыгына бәйле.

Карала торган эшкә карата кулланганда, югарыда санап үтелгән оештыру-процедура чараларының төп бурычы булып күпбалалы гаиләнең беренче чиратта сертификат алу өчен хокукый нигезләрен ачыклау, ә атап әйткәндә гаиләдә кимендә ун бала булу кебек ачыклаучы факторны билгеләү тора. Шул ук вакытта, ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертеп, беренче чиратта торак белән тәэмин итү хокукы барлыкка килү (тану) вакыты ачыклана, ә бу, үз чиратында, мондый гаиләләрнең Кагыйдәләр белән билгеләнгән срокта сертификат алу гарантиясе булып тора.

Шуның белән бергә, карала торган Кагыйдәләрнең хокукый нигезләмәләренең эзлекле тотнаклы логикасы нигезендә күпбалалы гаиләдә кимендә ун бала булу сертификат бирү этабында да кирәкле шарт булып тора. Шулай, Кагыйдәләрнең 20 һәм 22 пунктлары буенча Министрлык тапшырылган исәпкә алу эшләренең күчермәләре нигезендә сертификатларны рәсмиләштерә һәм аларны гражданнарга тапшыру өчен җирле үзидарә органнарына җибәрә. Шул ук вакытта турыдан-туры инде рәсмиләштерелгән сертификат алу өчен, Кагыйдәләрнең 23 пункты нигезендә, граждан җирле үзидарә органына Кагыйдәләргә 6 кушымта нигезендә билгеләнгән формада тиешле гариза һәм гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен раслый торган документлар тапшыра. Шул ук вакытта, аталган кушымтаның эчтәлегеннән һәм аны куллану практикасыннан чыгып, әлеге гариза граждан тарафыннан күпбалалы гаиләнең сан ягыннан составын һәм аның торак белән тәэмин итүгә мохтаҗлыгын раслау максатларында тапшырыла, бу фактта гражданнарны кабат тикшерүне аңлата, аның кысаларында сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертелгән вакытта гражданнарның булган шартлары – нигезләре, сертификат бирелгән вакытка аларда булган шартлар – нигезләр белән чагыштырыла.

Әмма юридик техника күзлегеннән караганда, Кагыйдәләрнең 17 пунктында каралган тәртиптә беренче чиратта сертификат алу хокукы сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертү юлы белән инде танылган гражданнарга карата үткәрелгән тикшерүнең мәгънәсен һәм эчтәлеген дөрес итеп аңлатырга мөмкинлек бирми торган Кагыйдәләрнең 23 пунктындагы билгеле бер җитешсезлекләрен дә исәпкә алмаска ярамый. Аерым алганда, норматив хокукый акт текстында күпбалалы гаиләнең беренче чиратта сертификат алуга хокуклылыгын, тиешле процедура карарларын кабул итү шартларын һәм нигезләрен кабат раслау бурычын билгели торган нигезләмәләр юк, шулай ук анда гражданнар тарафыннан теге яки бу карар белән килешмәүне белдерү мөмкинлеге беркетелмәгән. Моннан тыш, әлеге эштә карала торган мәсьәләгә карата сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертелгән гражданнар беренче чиратта сертификат алу шартларына туры килмәгән очракта Министрлык нинди карар кабул итәргә – сертификат бирүдән баш тартырга һәм (яки) сертификатлар алучы гражданнар исемлегеннән төшереп калдырырга – тиеш булуы аңлашылмый.

Гавами хакимият органнары тарафыннан нинди карарлар кабул ителергә тиеш булуы, шул исәптән аларның нинди нәтиҗәләргә китерүе турындагы мәсьәләдә җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпкә алу эше документларын тапшырмаган яисә тулысынча тапшырмаган очракта Министрлык тарафыннан сертификат рәсмиләштерелмәвен күз алдында тоткан Кагыйдәләрнең 21 пункты нигезләмәләре дә билгесезлекне юкка чыгармый. Аның гавами хакимият органнарының үзара бәйләнеше элементларының берсе булып торуы һәм Кагыйдәләрнең 23 пункты белән логик-хокукый бәйләнешкә ия булмавы сүзгә-сүз эчтәлегеннән ачыктан-ачык күренгәнлектән, юридик конструкциядән һәм әлеге норманың карала торган хокукый җайга салудагы урыныннан чыгып, аның максатчан билгеләнешен бер мәгънәдә аңлап булмый.

Тиешле җайга салу булмау сәбәпле Кагыйдәләрнең 23 пункты Кагыйдәләрнең 17 пунктындагы хокукый мәгънәсе белән каршылыкка керә һәм шуның белән аның, югарыда күрсәтелгәнчә, гаиләнең беренче чиратта торак белән тәэмин итүгә хокуклы булуы сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертелгән вакытта ук инде танылган булуында күренгән мәгънәсенең аермасын бетерә. Бу Кагыйдәләрнең 17 һәм 23 пунктлары белән беркетелгән шикаять белдерелә торган норманы гамәлгә ашыру механизмының бөтен тулылыгын какшата һәм ахыр чиктә сертификатны бирү максатын – ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак белән беренче чиратта тәэмин итүне шик астына куя.

Хокукый җайга салуның гамәлдәге моделе – исемлекләргә кертү административ тәртиптә гомуми рәвештә гамәлгә ашырылу, ә сертификатны бирү, Кагыйдәләрнең 23 пунктының турыдан-туры эчтәлегеннән чыгып, ситуациягә карап (ирекле) башкарылу – карала торган хокукка чынлыкта гамәлдә булмаган, ә иллюзор характер биргәнгә күрә конституциячел кабул ителми. Китерелгән билгесезлек дәгъва белдерелә торган норманың һәм Кагыйдәләрнең югарыда күрсәтелгән нормалары нигезләмәләрен саклауда, үтәүдә һәм куллануда бертөрлелеккә каршы килә һәм, димәк, хокук куллану практикасында каршылык китереп чыгара.

Шуның белән Татарстан Республикасы Конституция суды «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пункты, Кагыйдәләрнең 17 һәм 23 пунктлары нигезләмәләре белән тыгыз бәйләнештә булып, ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләнең сертификатны беренче чиратта алу хокукын билгеләп, Кагыйдәләрнең әлеге пунктларында билгеләнгән аны гамәлгә ашыру механизмында билгесезлек бар, бу конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен киметә, тигезлек һәм хокук өстенлеге, гражданнарның законга һәм дәүләт (гавами хакимият) гамәлләренә ышанычын саклау принципларын, шулай ук гражданнар хокукларының тотрыклылыгын һәм гарантияләнүен бозуга китерә дигән нәтиҗәгә килә.

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясендә, аның 1 (1 өлеш), 4 (2 өлеш), 15 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 19 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында беркетелгәннәрдән килеп чыга торган хокукый норманың ачыклыгы, төгәллеге һәм бер мәгънәдә булуы гомумхокукый критериен, хокукый дәүләт, закон өстенлеге һәм юридик тигезлек принципларын үтәмичә, аны бертөрле аңлау һәм, димәк, куллану мөмкин түгел; хокукый җайга салуның бер мәгънәле булмавы, ачык булмавы һәм каршылыклылыгы аның эчтәлеген төгәл аңлатуга каршы килә, хокук куллану процессында чикләнмәгән карау мөмкинлеген бирә, башбаштаклыкка китерә һәм шуның белән конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен какшата; шуңа күрә хокукый норманың билгелелеге таләбен бозу үзеннән-үзе мондый норманы Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килә дип тану өчен тулысынча җитәрлек булырга мөмкин (2011 елның 20 декабрендәге 29-П номерлы, 2015 елның 2 июнендәге 12-П номерлы, 2017 елның 19 июлендәге 22-П номерлы, 2018 елның 16 мартындагы 11-П номерлы һ.б. карарлар).

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды, акыллы тотнаклылык принцибына таянып һәм объектив килеп туган чынбарлыкны исәпкә алып, конституциячел яклана торган кыйммәтләр балансын саклау максатларында әлеге эштә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 732 номерлы карарындагы дәгъва белдерелә торган 4 пунктын, ул аны гамәлгә ашыру тәртибен җайга сала торган норматив хокукый нигезләмәләр системасында ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне беренче чиратта торак белән тәэмин итү максатларында сертификат бирү мәсьәләсен хәл иткәндә төрлечә якын килергә юл куйган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып калу мөмкин дип саный. Бу әлеге хокукый норманы хокук өлкәсеннән төшереп калдыру мондый гаиләләрнең беренче чиратта торак белән тәэмин итүгә булган хокукларын нигезсез чикләүгә китерергә мөмкин булуы белән бәйле.

Татарстан Республикасы Конституция суды, сертификатны рәсмиләштерү һәм (яки) бирү этабында кабат тикшерү уздыру үзеннән-үзе аны регламентлаштыручы хокукый җайга салу хокук кулланучылар һәм гражданнар өчен шул исәптән гражданнарга карата торак белән тәэмин итүгә хокукны гамәлгә ашыру турыдан-туры бәйле нинди процедура карарлары кабул ителергә мөмкин булуын алдан күрергә мөмкинлек бирә торган тулы, ачык һәм аңлаешлы эзлекле гамәлләр алгоритмы булганда гына акланырга һәм нигезләнергә мөмкин булуын ассызыклау кирәк дип саный.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына – Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге карарны исәпкә алып – күпбалалы гаиләләргә сертификат рәсмиләштерүне һәм бирүне регламентлаштыра торган, шул исәптән, әлеге тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган процедура карарларын һәм аларга карата шикаять бирү тәртибен күрсәтеп, алар тарафыннан сертификат алу өчен хокукый нигезләрне тикшерү административ процедураларын беркетеп, сертификат бирү тәртибенә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләре нигезләмәләрен бертөрле куллануны тәэмин итә торган үзгәрешләр кертергә кирәк.

Мондый нәтиҗә Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә тулысынча җавап бирә, ул, әгәр норманы аңлату, барыннан да элек суд актларында, аны интерпретацияләүдә тотрыклы аермалыкларны юкка чыгарырга мөмкинлек бирмәсә һәм башка нормалар белән чагыштырганда, йә үзе мондый аңлашылмаучанлыклар тудырса, аның хәтта конституциячел законнар белән үзара бәйләнешен чагыштырып караганда да тиешле аңлатылуы мөмкин түгел, шуның белән бергә туры килми торган нәтиҗәләр һәм хокук куллануның төрле вариантлары, һәркайсы аерым, хокукый җайга салуның теге яки бу конституциячел кабул ителә торган моделендә юридик нигезләрдән мәхрүм ителмәскә мөмкин; бу очракта норманы закон нигезендә төгәлләштерү тиешле хокукый җайга салуның гамәлдәге эчтәлеген ачыклауның, әгәр дә бердәнбер мөмкин ысулы булмаса да, аеруча корректлы ысулы булып тора, дип күрсәткән (2013 елның 23 декабрендәге 29-П номерлы, 2015 елның 2 июнендәге 12-П номерлы, 2015 елның 25 июнендәге 17-П номерлы һ.б. карарлар).

3.2. Социаль ярдәм чараларын бирү мәсьәләсендә хокукый мөнәсәбәтләр үзенчәлеге аларны җайга салуның мөмкин булган ысулларының күптөрлелегеннән тора, димәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты шактый дискрециягә ия, ләкин ул тигезлек, гаделлек һәм башка конституциячел принциплар белән чикләнгән, күпбалалы гаиләләрнең ихтыяҗларын мөмкин кадәр күбрәк канәгатьләндерерлек шундый хокукый җайга салу ысулын сайлауга омтылырга тиеш.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды гаиләдә ун һәм аннан да күбрәк бала булу, һичшиксез, мондый гаиләне беренче чиратта торак белән тәэмин итү өчен сертификат бирү мәсьәләсендә мөһим һәм әһәмиятле шарт булып торуын билгеләргә кирәк дип саный. Шул ук вакытта, ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләне сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертү вакытыннан алып сертификат үзе бирелгәнчегә кадәрге чорның дәвамлы булуын исәпкә алып, мондый күпбалалы гаиләдә гражданнарның ихтыярына бәйсез рәвештә көтелмәгән хәлләр булырга мөмкин, алар сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә мондый исемлекләргә кертүдән баш тарту өчен нигез була алыр иде, аерым алганда, беренче чиратта сертификат алу хокукына ия гаиләдә бала үлеме. Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына сертификатта күрсәтелә торган һәм бирелә торган торакның гомуми мәйданы күләмен яңадан исәпләү механизмын билгеләү мәсьәләсен ун һәм аннан да күбрәк баласы булган, сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә инде кертелгән һәм шуның белән бергә алар өчен беренче чиратлылык хокукын саклап калып, бирелгән хокукны гамәлгә ашыруны көткән күпбалалы гаиләнең фактагы сан ягыннан составыннан чыгып карауны максатка ярашлы дип саный. Бу гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклау принцибына җавап бирер иде, хокукый җайга салуның акыллы тотрыклылыгын саклап калуга һәм сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә кертелгән гаиләләр тарафыннан, дәгъва белдерелә торган норма белән гарантияләнгән сертификатларны беренче чиратта алу хокукын акланмаган чикләүгә юл куймауга, шулай ук әлеге максатларга бүлеп бирелә торган акчаларны нәтиҗәле файдалануга ярдәм итәр иде.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә тулысынча туры килә, аның эчтәлегеннән күренгәнчә, балалар туу һәм тәрбияләү белән бәйле рәвештә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары, гаиләне конституциячел-хокукый һәм традицион аңлауда, аны ныгытуга ярдәм итүгә юнәлдерелергә тиеш, шуңа бәйле рәвештә закон чыгаручы тиешле хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда мондый төрдәге чараларның максатчан юнәлеше булган бу өлкәне игътибарсыз калдырырга хокуклы түгел (2021 елның 29 июнендәге 30-П номерлы карар).

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. Әлеге эштә Татарстан Республикасы Конституция суды «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына – Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге Карарны исәпкә алып – күпбалалы гаиләләргә сертификат рәсмиләштерүне һәм бирүне регламентлаштыра торган, шул исәптән, әлеге тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган процедура карарларын һәм аларга шикаять бирү тәртибен күрсәтеп, алар тарафыннан сертификат алу өчен хокукый нигезләрне тикшерү административ процедураларын беркетеп, сертификат бирү тәртибенә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 ел, 18 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләре нигезләмәләрен бертөрле куллануны тәэмин итә торган үзгәрешләр кертергә кирәк.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 104-П **Татарстан Республикасы Конституция суды**

Яңа чынбарлыкта яши башлавыбызга нәкъ бер ай булып бара. Халык вазгыятькә мөнәсәбәтен товарларга ажиотаж рәвешендә күрсәтә әлегә. Газета хәбәрчесенең картасына кергән соңгы хезмәт хакының ярты ай эчендә очы күренде. Товар сатып алу марафонында катнашмаган килеш әле бу. Башка керемнәрең булмаса, утыр да ела. Туксанынчы еллардан соң беренче тапкыр акчасызлыкның ни икәнен татырга туры килде.


Илдар Мөхәммәтҗанов

БӘЯЛӘР МАРАФОНЫ

Башка гаиләләрдә дә хәл шундый дип уйласак, өйләрне складларга әйләндерү маршы озакламый тукталырга тиеш. Бәяләр төшәр дип өметләнеп булмый ләкин. Әйтик, менә шикәрне генә алыйк. Хәзергә ул бездә җитә. Россиянең кайбер төбәкләрендә әле дә эшкәртелмәгән шикәр чөгендере өелеп ята диючеләр бар. Димәк, заводлар чимал белән тәэмин ителгән. Ләкин «Российская газета» яза: «Россиянең агросәнәгать комплексында чит ил селекциясе орлыклары өлеше кукурузныкы – 58, көнбагышныкы – 73, шикәр чөгендеренеке 98 процентка җитә». Федерация Советының Аграр азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Алексей Майоров орлыклык бәрәңге һәм шикәр чөгендере орлыгы белән үз-үзебезне тәэмин итү вазгыятен катастрофа хәлендә дип бәяли. Россиянең Азык-төлек куркынычсызлыгы доктринасы исә үзебезнең орлыклар күләменең кимендә 75 процент булуын таләп итә. Үтәләме доктрина? Юк! Бу юлларның авторы ике еллар тирәсе элек бу мәсьәләне күтәргән иде. Дөресрәге, илкүләм сәясәтчеләр күтәргән иде аны, без теманы шәрехләгән генә идек. Фанфаралар сугылган, кылычлар айкалган, йөк урыныннан кузгалсын өчен берни дә эшләнмәгән. Хәзер менә башка күсәк белән суккан шикелле санкцияләр кертелде, доллар югарыга сикерде. Тиешле мәйданда чәчәрлек шикәр чөгендере орлыгы бармы-юкмы икәнен белеп бетермибез. Рәсми мәгълүматлар быелга җитәрлек орлык, химия һәм техника иске бәяләрдән сатылып алынды инде дип әйтәләр әйтүен.

Вазгыять бит нәселле терлекләр белән дә шундый ук. Орлык читтән кайтарыла. «Орлыгы Бохарада түгел» дигән татар әйтеме туры килми бу вазгыятькә. Үз терлекләребезнең нәселен генә үрчетсәк, җитештерелгән ит-сөт күләме кимү ягына таба китәчәк. Яхшы нәселле терлек китереп чыгару өчен кимендә 12 ел кирәк дип ишеткәнем бар. Үсемлек орлыклары белән дә шуңа якындыр инде ул.

Шул ук федераль хөкүмәт газетасы авыл хуҗалыгы техникасына хезмәт күрсәтү һәм запчастьлар да импортка бәйле дип яза. Быелгы авыл хуҗалыгы сезонын, табигать шартлары уңай килсә, яхшы гына ерып чыгарбыз дип өметләник. Аннан соң хәл кире якка да үзгәрә ала. Үзебезнең орлыкларны булдыру өчен, фәнни-тикшеренү институтлары челтәрен булдырасы, аларда эшлим дип торган сәләтле кадрларны табып, укытып-өйрәтеп, штатларны тутырасы бар әле.

Федераль хөкүмәт Рәисе Мишустин әфәнде сишәмбе көнне ил икътисадын тотрыкландыру өчен яңа чаралар пакеты турында сөйләде. Көнбатышлылар безгә санкцияләр пакеты белән яный, без чаралар пакеты белән җавап бирәбез ягъни. Әмма әлегә ай-ти тармак өчен кертелгән өстенлекләр тиешле нәтиҗәләрне биреп бетерми, мәсәлән. Айтичыларның байтагы чит илләргә февральдә үк күчте. Апрельдә яңа зур дулкынның чит илләргә китүе көтелә. Россия ягы Әрмәнстан һәм Грузиягә киткән белгечләрне мәҗбүри рәвештә илгә кайтарырга тели икән дигән имеш-мимеш хәбәрләр дә бар. Безнең программачылар белән Ташкент, Алма-Ата, Истанбул тулды инде, фатирга аренда хакы күтәрелде ул шәһәрләрдә. Сирәк очрый торган башка белгечләр дә күптән инде чит мәйданнарда. Шуңа күрә хөкүмәт бик зур тырышлык белән программалар төзи, әмма аларның үтәлеше йөз процент ук була алмас. 70–80 процентка уңышка ирешсәк тә, яхшы булачак. Сүз берничә еллык тырышлыктан соң гына килә торган уңыш хакында бара. Эшне тизләтү өчен, Мәскәүгә Әнкара белән аркадашлык итсә яхшы. Кытай товарлар белән булыша ала, әмма технологияләр белән ярдәм итүе икеле. Аның максаты бездән чимал алып, технологик товарлар белән тәэмин итү. Төркия исә алгарыш өчен төньяк күршесе белән хезмәттәшлек итүгә каршы түгел, чөнки, ни дисәң дә, Мәскәүнең төрекләргә тәкъдим итәрлек кайбер нәрсәләре бар. Әрдоган яңа гына Metaverse дигән форумда катнашты һәм: «Безнең илебезнең потенциалы шулкадәр бөек: ул үз Кремний үзәнен булдыра алыр иде», – дип чыгыш ясады. Бу буш сүзләр түгел, чөнки төрек инновацияләре кайбер өлкәләрдә дөньякүләм лидерлыкны яуларга омтыла. Россиянең юкка чыккан куәтләрен торгызу өчен менә дигән аркадашлар инде. Әмма барыбер сүз ерак киләчәк хакында бара.

Бүген исә безгә алдагы сезонда үзебезне азык-төлек белән тәэмин итү генә түгел, бәяләрнең кесә күтәрә алырлык булу мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк булачак. Монысы да зур нәрсә әле аның. Халык интуитив рәвештә аңлый моны һәм, кибетләргә чапканда, хәзерге көнне генә түгел, алдагы айларны да кайгырта. Татарстанда бәяләр санкцияләр кертелгәннән соң болайрак үскән. Шикәр бәясенең 25 февральдә килосы уртачача 59,63 сум булса, 17 мартта – 81,53. Бодай оны февральдә – 45,09, мартта – 48,29. Тоз санкцияләр алдыннан – 12,69, хәзер – 15,88. Барысы да – үзебездә җитештерелгән һәм җитәрлек товарлар. Районга карап бәяләр нык аерыла ләкин. Мөслим районында 17 мартка шикәр бәясе 109,51 сумга җиткән, Арчада – 83,50, Югары Осланда – 60,79. Тоз Әлкидә – 21,33 сум, Чирмешәндә – 9,49 сум. Район белән район арасында бәяләрнең мондый аермасы бу юллар авторы өчен сер булып кала. Бозылмый торган товарлар хакында сүз бара бит. Димәк, тырышканда базар ысуллары кулланып та бәяләрне ике тапкыр диярлек төшерергә мөмкинлек бар. Барлык төр азык-төлек позицияләре белән дә хәл шундый диярлек: иң югары бәя белән иң түбән бәя якынча ике тапкыр аерыла.

Бәяләрнең мондый сикереше җитештерү мөмкинлекләренә ышанмаудан гына түгел, милли валютага ышаныч булмаудан да. Кешеләр товарны күпләп җыйганда, аны бартерга алыштыру мөмкинлеген дә күз алдында тота. Шикәр дигән валютаны мәйданга чыгармакчы булалар. Югары икътисад мәктәбе галиме Игорь Липцис: «Бартер, блат, азык-төлек заказы» дигән онытылган сүзләрне яңадан искә төшерергә туры килер, әмма Россиядә куркыныч социаль-демографик катастрофалар булмас», – дип фаразлый. Бартерның мәйданга чыгуы да ил өчен бик начар нәрсә инде ул. Салым түләү туктала, финанс системасы түбәнгә тәгәри, хезмәт хаклары түләнми, түләнсә, товарлар белән дигәнне аңлата монысы. Федераль хөкүмәтнең төп тырышлыгы тотрыклы һәм ышанычлы акча белән тәэмин итү булырга тиеш. Менә шуңа ирешә алса, икътисад үзе хәрәкәткә килә ул. Киткән кадрлар да кайта, программалар да эшли башлый. Шуңа ирешелми икән, без даими ажиотаж, бетми торган дефицит белән очрашачакбыз. Көнбатыш катгый санкцияләр керткәндә, менә шуңа исәп тотты да инде. Халыкта ризасызлык уятып, фетнә чыгаруны күз алдында тотты. Бу өлкәдә аның тәҗрибәсе бар бит. СССР нәкъ шулай җимерелде. Башта акчага ышанычны юк иттеләр, аннан соң ил икътисади яктан түнде, аннан соң сәяси кризис мәйданга чыкты. Менә шуны кабатларга тырышалар. Бүген халык шикәр чиратына баскан икән, бәяләр марафоны безне социаль тетрәнү дигән финишка алып килергә ихтимал.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Икмәксез калмабыз

ТАТАРСТАНДА ОН ЗАПАСЫ ҖИТӘРЛЕК

Соңгы араларда Татарстанда икмәккә ихтыяҗ арткан. Моңа карамастан, республикада камыр ризыкларына кытлык көтелми. Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков, социаль икмәк элеккеге күләмдә һәм сыйфатта җитештереләчәк, дип ышандырды.

realnoevremya.ru

Социаль ипигә бәя артмый

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов йөкләмәсе буенча, республикада он, шикәр һәм башка төп азык-төлек продуктларының резервы булдырылды. Икмәк пешерү предприятиеләренә акчалата да ярдәм итәчәкләр. Бу максатларга 240 млн сум акча каралган.

– Продукциянең үзкыйммәтенең нигезе булган он икмәк пешерүчеләргә 45 көнгә кичектереп сатылачак. Республика тарафыннан 3 мең тонна шикәр сатып алынды. Икмәк пешерүчеләргә шикәр тотрыклы бәядән биреләчәк, – диде Наил Залаков.

Республиканың икмәк пешерүче иң эре предприятиеләренең берсе – Күмәч-кондитер комбинатында тәүлегенә 60 тонна ипи һәм икмәк эшләнмәләре җитештерелә. Предприятие кибет киштәләрен икмәкнең барлык социаль төрләре, икмәк-күмәч, кондитер эшләнмәләре, аерым алганда, торт, пирожный һәм чәкчәк белән тәэмин итә. Биредә 700дән артык кеше эшли. Без килгәндә, предприятиедә яңа пешкән камырның хуш исе таралган, эшнең иң кызган чагы иде. Икмәк пешерүчеләрнең куллары-кулга йокмый, күмәчләр мичләргә озатыла һәм өсләре алланып, тәмле булып пешә. Биредә эшләүчеләр инде иртәдән аяк өстендә. Әллә кайдан күренеп тора: үз эшләрен яратып башкаралар.

Соңгы өч атнада ипинең социаль сортларына ихтыяҗ арту күзәтелә. Аеруча «Сельский» һәм «Дарницкий» төрләрен күпләп алалар икән. Бу хакта журналистлар белән очрашуда комбинатның генераль директоры Булат Котдусов әйтте. Сатып алу арту аларның бәясе арзанрак булуына бәйледер, ди ул. Социаль ипигә бәяләрне саклап калу өчен коммерцияле продуктларга бәяләр 10 процентка кадәр күтәрелергә мөмкин.

– Узган ел дәвамында бездә барлык бәяләр буенча индексация 6 процент иде, чимал 13 процентка кыйммәтләнде. Без һәрвакыт бәяләрне тотрыклы тотарга тырышабыз, – ди җитәкче.

Ваклап сату предприятиеләре соңгы өч атнада Күмәч-кондитер комбинатына гаризалар күләмен 3–5 тоннага арттырган. Әгәр элек предприятиедән тәүлегенә 55–60 тонна продукция җитештерүне таләп итсәләр, бүген – 59–63 тоннага кадәр. Генераль директор әйтүенчә, предприятиедә кимеми торган он запасы 300 тоннаны тәшкил итә. Шикәр, май, чүпрә кебек төп азык-төлек продуктлар запасы да җитәрлек.

Импортка бәйле түгел

Булат Котдусов сүзләренчә, предприятиедә Таиландтан кайтарыла торган экзотик җиләк-җимеш белән тәэмин итүдә өзеклекләр бар.

– Әлегә экзотик продуктларны китерү сроклары буенча логистик сораулар бар. Тропик җиләк-җимеш запасы җитә. Бөтенләй булмаган очракта да, эчлеккә күрәгә яки башка җиләк-җимеш тә салып була, – ди ул.

Икмәк комбинатында камыр әйберләрне эшләү өчен яңа заманча технологияле җиһазлар урнаштырылган. Техник җиһазларның берсе эшләгәндә, калган икесе резервта тора. Запас частьларга да кытлык юк. Аларны бер елга җитәрлек алып куйганнар икән. «Чит илнекен алыштыра алырлык запас частьлар Россиядә дә бар. Без импортка бәйле түгел, санкцияләргә дә эләкмәдек», – ди җитәкче.

Предприятиенең төрү материаллары запасы да 2–3 айга җитә әле. Ә бәяләр 25–30 процентка артыр дип фаразлый Булат Котдусов. Чөнки төргәк өчен чит ил компонентлары кулланыла. Ипи пешерүчеләр исә бәяләрне тотрыкландыру өчен төрү материалларыннан бөтенләй баш тартырга тәкъдим итәләр.

Ләйсән САФИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ИЛӘБӘР ӨЛКӘННӘРЕ:

«ЯШИСЕ КИЛЕП ЯШИБЕЗ!»

Аларның йөзләрендә елмаю, күзләрендә нур балкый. Үзләрен «Иләбәр әбиләре» дип атасалар да, алар кызлар кебек. Берсен дә әби дияргә тел әйләнми. Колхозда авыр эшләрдә эшләп, лаеклы ялга чыксалар да, әле дә тик утырмыйлар икән. Бер дә зарланмыйлар, тормышны яратып яши алар. Узган атнада редакциябездә Саба районының Иләбәр авылы өлкәннәре кунакка килде. 17 кешедән торган бу төркем безне үзләренең гыйлемле, бар нәрсәдән хәбәрдар булулары белән шаккатырды.

Иң элек алар «ВТ»ның ничек эшләвен күзәтте. Журналистлар янына кереп үз сорауларын биреп, теләкләрен әйтеп чыктылар. Корректор кызларыбыз янында да кунак булдылар. Язмаларны ничек итеп газета битләренә салганны да күрделәр. Егетләр дә Саба «кыз»ларына сокланып калды. Ә аннары сөйләшү чәй өстәле янында дәвам итте. Иләбәрлеләр буш килмәгән, Гөлфәния Хөсәеновaның килене Алинә «Ватаным Татарстан» дигән торт та пешереп җибәргән. Өлкәннәр газетада чыккан язмалар хакында озак сөйләште. Һәр журналист хакында сорашты. Ә без исә аларның үз тормышлары белән кызыксындык.

Өлкәннәр авылдагы «Ак калфак» оешмасына да йөри икән. Нинди генә чара узмасын, шушы ханымнардан башка булмый. Аларны китапханәче Вәсилә Галиева белән мәдәният йорты җитәкчесе Рамил Хафизов бер йодрыкка туплап тота. Өлкәннәр үзләре дә аларга рәхмәтле икәнен яшерми.

– Кая гына йөртмиләр инде! Автобус яллыйбыз да, чыгабыз да китәбез. Бүген башта сезгә кердек, аннан соң концерт карарга китәбез. Вирустан куркып ятмадык без. Гел йөреп тордык. Шөкер, барыбыз да исән-сау. Тик тормавыбыз, гел хәрәкәттә булуыбыз ярдәм иткәндер, – ди гомере буе сыер савып ялга чыккан Сания Нигъмәтҗанова.

Бу төркем гомумән тик тора белми икән. Инде күпләр беләдер: кышын тау шуучы әбиләр шушылар инде. Чана белән генә чикләнмиләр, чаңгыга да басканнар. Кичләрен скандинавия таяклары белән дә йөриләр икән әле. Сәламәтлекләрен кайгыртырга вакыт табалар. Җәен самавыр белән табигатькә чыгып ял итәләр. Авырулары хакында да күптән онытканнар. Элек юлга чыкканда үзләре белән кан басымы үлчи торган аппарат алып, шәфкать туташын да ияртеп йөргәннәр. Хәзер инде состав та яшәргән, дарулар да тыгып йөрүләр беткән. Яңа гына пенсиягә чыккан 57 яшьлек ханымнар да килеп кушылган. Иң өлкәннәренә 70 яшь икән.

Бу юлы алар Казанга хат ташучы Гөлнараны ияртеп килгәннәр. Пенсионерлар аны бик яратабыз диләр. Әле хат ташучыга ярдәм булсын дип, сатудагы товарларын да алалар, күп итеп газета-журналларга да язылалар икән.

Әле менә шушы көннәрдә генә Вәсилә белән Рамил өлкәннәрне авылдагы фермага экскурсиягә алып барганнар. Элек сыер сауган, мал караган апалар хәзерге шартларны күреп, кызыгып кайткан.

– Тагын да эшләр идек әле. Җитәкчегә дә әйтеп төштек – сыер савучы җитмәсә, хәбәр бирегез, дидек. Без эшләгән чакларны искә аласы да килми. Әмма бигрәк нык булганбыз инде. Мин фермага 16 яшемдә урнаштым. Ул чакта җитәкче, йокы күрмисез инде, сабыйлар, дия иде. Үзебез сыер саудык, астын чистарттык. Ашарына салдык, сөтен ташып тапшырдык. 19 яшемдә сыерларны аппарат белән саварга тотындык. Тыңлатып та булмый иде. Әмма яшьлек белән көч җиткән, – ди Гөлфия Әхмәтшина.

Хәзер бар да башкача. Сыерны бер кеше сава, астын икенчесе чистарта, ашарына өченчесе бирә. Сөт торбалар буйлап кына китә.

Эшләр идем, дип кенә калмый икән бу өлкәннәр. Авылдагы фермерларга барып эшләп кайталар. Суганын да утырталар, бәрәңге басуында да эшлиләр. Пилорама тотучы егеткә дә ярдәм итәләр икән.

Ял турында да онытмый алар. Һәр атнаның чәршәмбесендә китапханәгә җыелалар. 28 ел китапханәче булып эшләгән Вәсилә Галиева аларның килүенә шат кына.

– Мин алардан яшәү көче алам. Шулкадәр белемгә омтылалар. Берәр яңа китап кайтса, үзем дә укып чыга алмыйча калам. Шушы апаларда йөри ул. Хәзер остардылар, китапны тапшырып та тормыйлар. Берсе укып бетерә дә икенче күршесенә бирә. Миңа шул кешегә күчер дип кенә шалтыратып әйтәләр. Китап миңа, бөтен авылны әйләнеп, берәр айдан кайтып җитә. Газеталарның бер хәрефен дә калдырмыйлар. Алар сканворд чишәргә бик тә ярата. Пыр тузып чишеп куялар. Һәркайсының кесәсендә ручка йөри, – ди Вәсилә ханым.

Өлкәннәр үзләре, китапханә – икенче өебез, дип шаярта. Алар монда килгәч, ни генә эшләми икән. Китапка анализ, республика газета-журналларына күзәтү ясыйлар. Бәйрәмнәрдә табын корып чәй эчәләр, туган көннәрен дә биредә үткәрәләр. Әле физик күнегүләр дә ясыйлар икән. Үзләренең махсус ковриклары, туплары бар.

Өлкәннәр мәчеткә дә йөри. Төзелештә эшләп лаеклы ялга чыккан Зөлфирә Галимуллина күңел дә ача, намазын да калдырмый.

– Рәхәтләнеп яшибез. Бергә җыелып аралашуга ни җитә соң?! Кызлар белән очрашкач, бар борчулар онытыла, – ди ул. – Ураза аенда тәравих намазларына йөрибез. Бергәләп йөрү күңелле инде. Әле менә кичә берничә дус җыелыштык та Өтернәс авылында яңа төзелгән мәчеткә төшеп, намаз укып мендек. 4 километр җәяү йөреп кайттык. Мин үзем оештыру эшләрен яратам, уйлыйм да, эшлим дә. Куркып торсаң, берни булмый.

Өлкәннәр үз авыллары хакында да сөйләде. Почти шәһәрчә яшибез, ди алар. Авыллары елдан-ел зурая икән. Соңгы елларда ике яңа урам төзелгән. Барысында да яшьләр яши. Авылдан китмәүчеләр күп. Озакламый авыл урамнарына асфальт керәчәк. Быел бакчаларны зурайтасы булыр, дип тә куйдылар. Иләбәрлеләр капчыклап шикәр дә җыймаган, ярма да алмаган. Акча булса, кибеттә товар бетмәс, ди алар.

«ВТ» коллективы белән очрашудан соң алар Вәсилә Галиева һәм Рамил Хафизовка тагын бер кат рәхмәт укыды.

– Безнең көйне көйләп йөриләр. Рәхмәт йөзеннән үзебез дә мәдәни чараларда катнашабыз, – ди Сания апа. – «Ватаным Татарстан» коллективына иҗат уңышлары телибез. Әле ярый сезнең янга килдек. Күңелләр күтәрелеп китте. Газетаны кулга алып укыганда гына рәхәт. Күпме көч һәм хезмәт кергәнне күреп китәбез. Һәр журналистның язмаларын яратып укыйбыз. Риман Гыйлемханов белән Марат Кәбиров аеруча якын. Дуслыгыбыз дәвам итсен, аралашып торыйк.

Әлеге өлкәннәрнең татар матбугатына булган карашы бөтенләй башка. Алар һәр сүзнең кадерен белеп, шуны язган кешенең хезмәтен дә бәялиләр. Үзләре белән теләсә нинди темага сөйләшеп була. Яшь аермасын да сизмисең. Яшермим, шәхсән үзем бу өлкәннәргә карап сокландым. Менә нинди булырга тиеш ул замана әбие! Онык та караша, үзен дә онытмый, башкаларны да кайгырта. Күңел хөрлеге, яшәү дәртегез беркайчан да кимемәсен!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

КӘШӘКӘ, АЛКА, ГОЛ...

Хоккей турында кем күбрәк белә?

1. Хоккей ватаны кайда?
А) АКШ;
Б) Канада;
В) Шотландия.

2. Беренче хоккей матчы кайсы елда оештырылган?
А) 1875;
Б) 1990;
В) 1940.

3. Матч вакытында боз мәйданында бер командадан берьюлы ничә кешенең уйнавы рөхсәт ителә?
А) 10;
Б) 5;
В) 6.

4. Буллит ул – ...
А) матч тәмамлангач та, өстәмә вакытта уйнау;
Б) уенчы белән капкачының «бергәбер» уйнавы;
В) капкачының кәшәкәсе шулай атала.

5. Хоккей буенча беренче дөнья чемпионаты кайсы елда уза?
А) 1945;
Б) 1918;
В) 1920.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) В; 4) Б; 5) В.

Киңәш-табыш

Чамасын белеп макта

Һәр балага тәмле сүз, мактау кирәк. Әмма аны кылган һәр гамәле өчен үсендереп тору кирәкме? Психологлар киңәшенә күз салыйк әле.

1 Баланы гади һәм җиңел бирелә торган гамәлләре, табигый сәләтләре өчен мактау дөрес түгел. Моның күбрәк тискәре йогынтысы булачак. Көч һәм тырышлык таләп ителгән, җиңел ирешелмәгән гамәлләр өчен лаеклы сүзләрне ишеттерергә киңәш ителә.

2 Вакытын белеп кенә мактарга кирәк. Бала андый сүзләргә ияләшергә тиеш түгел. Юкса ул аны һәрвакыт таләп итәчәк һәм көтәчәк. Бала нәрсәне дә булса мактау өчен түгел, өйрәнү, нәтиҗә өчен эшләргә тиеш. Мактау сүзләре ишетми икән, ул башкаларның уңышына карата көнче, вакчыл булып үсәчәк.

3 Мактауның бәһасе төшмәсен өчен, аны еш әйтергә ярамый. «Мине барыбер мактаячаклар» дигән хис тумасын.

4 Баланың шәхси сыйфатлары өчен түгел, ә казанышлары өчен мактау сүзләре әйтү дөресрәк. Югыйсә аның борыны күтәреләчәк. Артык югары үзбәя – бер дә матур күренеш түгел.

АЛИЯ САБИРҖАНОВА:

«Әни табиб булуымны теләсә дә, хыялларыма каршы килми»

Чираттагы яшь кунагыбыз – «Шаян ТВ» телеканалы алып баручысы һәм булачак театр артисты Алия САБИРҖАНОВА. Аның белән телевидение, сәхнә һәм хыяллар турында сөйләштек.

БЕЛЕШМӘ
- Алия – Илсөяр һәм Алмаз Сабирҗановлар гаиләсендәге өлкән бала. Аның Әдилә исемле сеңлесе бар.
- Ул Казанның 27 нче гимназиясендә 6 нчы сыйныфта белем ала.
- Киләчәктә йә алып баручы, йә театр артисты булырга тели.
- Волейбол һәм бадминтон белән шөгыльләнә.

:: Алия, «Шаян ТВ»га килүең турында сөйлә әле.
– Мин «Дулкыннар» исемле конкурста катнаштым, анда жюрида «Шаян ТВ» директоры Рамилә апа Сәхабетдинова да бар иде. Чыгышымны тыңлаганнан соң «Шаян ТВ»га кастингка чакырды. Кастингны уңышлы үтеп, шунда калдым.

:: Телевидение дөньясында кайнау ошыймы сиңа? Үзеңне киләчәктә бу өлкәдә күрәсеңме?
– Әлбәттә, ошый. Киләчәктә мин үземне йә алып баручы, йә театр артисты итеп күрәм. Мин «Нур» театр студиясенә яратып йөрим, «Зәңгәр шәл» спектаклендә катнашам. Сәхнәдә булу миңа бик ошый.

:: «Шаян ТВ»да нинди тапшырулар алып барасың?
– «Шаян ТВ»да иң беренче алып барган тапшыруым «Балачак илендә» дип атала. Аннары озак вакыт Илназ белән бергә «Шаян балалар» тапшыруында эшләдек. Шулай ук «Сәйлән» музыкаль телевизион фестиваленең беренче сезоны алып баручысы булдым. Ә узган ел «Тима һәм Тома» мультфильмында Томаны тавышландырдым.

:: Синеңчә, алып баручы эшендә иң мөһиме нәрсә?
– Һәр эштә дә иң мөһиме – тырышлык, ә алып баручыда – матур сөйләм теле һәм камерадан курыкмау.

:: Ә сәхнә нәрсәсе белән ошый?
– Мин игътибар үзәгендә булырга яратам. Иң ошаганы – спектакль беткәч, тамашачы алдына баш иярга чыгу.

:: Театрда уйнау теләгеңә әти-әниең нәрсә ди?
– Әти дә, әни дә моңа уңай карый. Иң мөһиме – эшне ярату, ди алар. Әни табиб булуымны теләсә дә, хәзерге хыялларыма каршы килми.

:: Театр студиясенә дә йөрисең, «Шаян ТВ»да да алып барасың, буш вакытың каламы соң? Барысына да ничек өлгерәсең?
– Вакытны дөрес бүлсәң, барысына да өлгереп була.

:: Берара «Инстаграм»да видеорецептлар урнаштыру белән дә мавыгып алгансың. Үзеңне блогер буларак таныту теләге идеме бу?
– Юк, блогер булырга теләмим, чөнки алар бик күп вакытын телефонда уздыра. Рецептларны без әни белән бергә төшердек. Сыйныфташларым шул видеолардан үзләре дә өйдә пешереп карап, аннары мәктәпкә килгәч, ничек пешергәннәрен миңа сөйлиләр иде. Хәзер дә әни белән бергә пешерәбез, видеога төшерергә генә вакыт җитми.

:: Яраткан актерың яки актрисаң?
– Театр артистларыннан – Алинә Мөдәрисова, Алмаз Сабирҗанов. Кино артистларыннан Федор Добронравовның уйнавы ошый.

:: Үзең кинода уйнарга теләр идеңме соң?
– Андый тәкъдим булса, бик шатланып кинода төшәр идем. Минем андый тәҗрибәм дә бар. Мәктәптә «Тукай варислары» дигән фильм төшергән идек. Шулай ук «Прохлада глаз» дип аталган фильмның өзегендә төштем, ә әти анда баш рольне уйнады. Алсу һәм Азат Фазлыевларның «Бәхетле бул, рәхмәтле бул» клибында да төштем. Кечкенә генә роль булса да, миңа бик ошады.

:: Бүген син нәрсә турында хыялланасың?
– Быел җәен «Сәләт» лагерена барырга хыялланам. Минем анда булганым бар инде. Шулай ук дөньяның имин-тыныч булуын телим.

Ләйсән САФИНА

ТАБИГАТЬКӘ САКЧЫЛ КАРАШ

Хикәя

Үз хатаңны үзең төзәт

Бүген иртәдән үк кояш җылырак карый. Ял көне булса да, йокы качты. Эх, бүген ташу тагын да катырак агар инде. Күпер катына гына төшәрменме икән, су буена төшәрменме? Татлы уйлар белән иркәләнеп ятканда, әбием чәй эчәргә чакырды. Мин әле бик иртә дип торам, инде сәгать тугыз булып киткән икән. «Бәхетеңне йоклыйсың, кызым», – дип төрттерергә дә җитеште әбием. «Әнә күршең Сәлим инде тышта әтисенә канау казырга булыша».

Тышка чыксам, Сәлим инде күпер катына төшеп киткән. Мин дә аның артыннан киттем. Ул әле җебергә җитешмәгән боз кисәкләрен аягы белән ватып уйный. Нишләптер, аягындагы итеге таныш сыман тоелды. Тик торганда Сәлимгә ачуым чыга башлады. «Кызлар итеге кигәнсең бит», – дип әйтеп тә куйдым. Итек мине бераз кыса да башлаган иде, булса да, эчемне пошырды, ул бит минеке. «Итегем тишелгән иде, авыл кибетләрендә миңа яраклысы булмады, районга иртәгә генә баралар, әни сездән алып чыкты бугай», – диде Сәлим. Минем уенда гамем калмады, ничек инде минем итек икенче кешедә? «Бу – минем итек, әйдә кайтабыз да, миңа итекне салып бирәсең», – дидем. Шулай эшләдек тә. Нишләптер Сәлим дә каршы килмәде. Мин баскыч төбендә итекне салдырып алдым да чыгып киттем. Өйгә кайтып, әбине дә ачуланып ташладым. «Кызым, бу итек сиңа юка носки белән генә ярый инде, сиңа икенче матур итек алдык бит. Алай саран булырга ярамый, син сорап кергәч, алар бирмәсә, рәхәт буламы?» – диде әби. Миңа оят булып китте. Чынлап та, нәрсә булган инде? Беркөнне дәфтәр сорап кергәч, Сәлим биреп торды бит. Нишләдем инде мин? «Әби, син генә кире кертеп бир итекне», – дип ялындым. «Юк, кызым, үз хатаңны үзең төзәтергә өйрән, бүтән бу хатаны ясамаска уңайрак була ул, аннан гел мин сиңа ияреп йөрмәм бит», – диде әбием. Мин оялып кына итекне кире керттем. Шелтәләп бер сүз әйтүче дә булмады. Кара әле, нинди яхшы икән бит безнең күршеләр! Үземә дә рәхәт булып калды. Бүтән болай эшләмәм дип, үз-үземә сүз биреп, чыгып киттем.

Лилия КАМАЛИЕВА, 14 яшь, «Глаголица» бәйгесе җиңүчесе.
Киров өлкәсе Малмыж шәһәре

Шигърият

БУЛ КӨЧЛЕ

Көчле булырга өйрәт син, язмыш!
Төз торырга кирәк ләбаса!
Җиңел булыр иде йөрәгемә,
Күңелкәем шуны аңласа...

Ул көчне мин каян табыйм икән?!
«Елама», – дип, тешне кысамын.
Тормыш битендәге артта булган
Ялгышларны сызып-бозамын.
Булыр бәхет, диеп янамын.

ЯРАЛАР

Нигә бәйләп булмый яраларны?
Минем яра нигә бәйләнми?
Нигә икән минем яраларым
Тиз юл белән үзе көйләнми?
Нигә бәйләнмиләр бу яралар?
Йөрәк серләремне кем белгән?
Горур атлап барган чакта мине,
Абынды, дип сөйли... Кем күргән?
Нигә бәйләп булмый яраларны?
Нигә йөрәк һаман бозлана?!
Күңелкәем урын таба алмый,
Бертуктамый янә сызлана.

КАДЕРЛӘРЕН БЕЛМИБЕЗ

Нигә тормыйбыз сүзләрдә,
Олы вәгъдәләр биргәч?
Яшь түгәбез үкси-үкси,
Бер кочасы иде, диеп,
Кабер янына килгәч.

Тик кайтарып булмый икән
Бердәнбер әни затын!
Вакыт үткәч, кирәкмәс шул
Хәтта бер кисәк алтын.

Әниләргә булган хөрмәт
Кая китеп югала?
Кадерләрен белмибез шул...
Үз башыңа төшкәч кенә,
Җан кителгән пыяла.

УЯН, КЕШЕЛЕК!

Үзгәрде шул бу кешелек,
Куркудан йөрим качып.
Дус иткәнең дошман була,
Йә бер «убырлы карчык».

Битлек кигән албастылар
Арттан куа баралар.
Әйткән үткен сүзләреннән
Төзәлерме яралар?

Сөйли калсаң берәрсенә,
Чыгарырлар юләргә.
Куанырлар: «Бу ахмактыр», –
Сәбәп булыр көләргә.

И кешелек, зинһар, айны,
Ач инде күзләреңне.
Бас намазга, тәһарәт ал,
Нурла, дим, йөзләреңне.

НИГӘ ЕЛЫЙ АНЫҢ ЙӨРӘГЕ?

Бу авылда сукыр ата йорты,
Кемне көтә аның күзләре?
Көтү газабыннан тәне туңа,
Саргайган күк аның йөзләре.

Бу авылда сукыр ата йорты,
Нигә елый аның йөрәге?
Оныклар һәм балаларын күрү –
Бу тормышта иң зур теләге.

Бу авылда сукыр ата йорты...
Намазлыгын ала кулына.
И Ходаем, зинһар, ишет мине,
Сип син гөлләр аның юлына!

Бу авылда сукыр ата йорты,
Бәетен ул сөйли башлады.
Сорау бирде: «Балаларым, нигә
Күңелегез мине ташлады?»

Эльвина ШАКИРОВА,
10 нчы сыйныф укучысы.
Балтач районы Норма авылы

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 242

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+